Риторика дәресләре

3

«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

М. Х. Хәсәнова, Г. М. Сафиуллина,
М. Я. Гарифуллина, Ә. Г. Мөхәммәтҗанова

Риторика дәресләре

3 нче сыйныфта эшләүче укытучылар өчен
методик кулланма

*Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы
рөхсәте белән басыла*

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 372.016: 821.512.145*03
ББК 74.268.4:84(2Рос=Тат)
Р51

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Риторика дәресләре: 3 нче сыйныф: Укытучылар өчен
Р51 методик кулланма / М. Х. Хәсәнова, Г. М. Сафиуллина, М. Я. Гарифуллина, Ә. Г. Мөхәммәтҗанова.— Казан: Мәгариф, 2004.— 63 б.
ISBN 5-7761-1344-х

Бу методик кулланмада һәр дәресне ничек үткәрергә кирәклеге җентекләп сурәтләнгән. Укытучының сораулары гына түгел, көтелгән җаваплар да бирелгән. Берничә вариантта тәкъдим ителгән өй эшләрен укытучы үзе сайлап та, рәтләргә бүлеп тә бирергә мөмкин. Укучыларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, дәрес үрнәкләреннән иҗади файдаланырга кирәк.

ISBN 5-7761-1344-х © «Мәгариф» нәшрияты, 2004

КЕРЕШ

Соңгы елларда республикабызда «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру юнәлешендә күп эшләр башкарылды. Дистәләрчә еллар дәвамында ана телебезгә ят булган интонацияләр, ярымрусча-ярымтатарча гыйбарәләр, калькалаштырылган җөмләләр, тупас сүзләр үтеп керүен исәпкә алып, татар сөйләме культурасын үстерү мәсьәләсенә дә зур игътибар бирелә башлады.

Татар телен хәрәкәттә өйрәнүче һәм өйрәтүче фән тармагы — риторика аякка басып килә. Риторика фәне буенча беренче дәреслек һәм кулланмалар барлыкка килде. Дөресрәге, риториканы өйрәнү юнәлешендә электән — әле мәдрәсәләребездә үк тупланган традицияләр кайтарыла башлады.

Өченче сыйныф укучыларына тәкъдим ителә торган дәреслек — шушы өлкәне үстерергә өлеш кертә торган бик вакытлы хезмәт. Аның авторлары һәм Балтач районы башлангыч сыйныф укытучылары тарафыннан 10 еллап практикада сынап каралган хезмәт.

Дәреслектә, фикерне белдерү чарасы буларак, текстның мөмкинлекләре ачыла. Балаларга фикерләү барышында дәлилнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуы кызыклы мисаллар ярдәмендә аңлатып бирелә. Фикерләгәндә берничә дәлил, әсәрдән өземтә, мәкальләр куллану 3 нче сыйныф укучысына аңлаешлы итеп бирелгән. Нәтиҗә ясарга өйрәтү дә — бик әһәмиятле темаларның берсе.

1 нче һәм 2 нче сыйныфларда ук башланып, 3 нче сыйныфта да котлау текстлары язарга, кунакка ничек чакырырга һәм анда үзеңне ничек тотарга өйрәтү дәвам ителә.

Риторика фәне өчен мөстәкыйль фикер йөртергә, текст төзергә өйрәтүнең әһәмияте әйтеп бетергесез зур. Бу фән укучыларның үз иҗатларын активлаштыруга да юнәлдерелгән.

Шулай ук бу дәресләр баланы үзе, гаиләсе турында дөрес, аңлаешлы һәм үтемле итеп сөйләргә, нәсел җебе — шәҗәрәләре белән кызыксынырга, аны төзергә өйрәтә. Дәреслектә сөйләмне оештыруда интонация, дикция, орфоэпия үзенчә-

лекләре, ишарәләр һәм мимика кебек телдән тыш чаралар да исәпкә алынган. Аерым сүзләрнең, җөмләләрнең әйтелеше, сүз һәм сүзтезмәләрдәге басым, сөйләмнең синтагмаларга бүленеше, авазлар әйтелеше, сөйләм техникасы, сөйләмнең темпы һәм ритмы, интонацион-мелодик яңгырашы — боларның барысына да тиешле урын бирелгән, укытучы да зур игътибар бирер эшләргә тиеш.

Китап укучыларга татар риторикасы һәм сөйләменең гаять катлаулы табигатен киң масштабта — матур әдәбияттан, публицистикадан һәм башка өлкәләрдән алынган күп санлы мисаллар нигезендә өйрәтүне төп максат итеп куя. Укытучы, дәрескә бирелгән барлык материалны файдаланмыйча, үзе тиешле санаганын гына куллана ала. Укучыларның әзерлек дәрәҗәләре төрлечә булганлыктан, методик кулланмаларда өй эше дә берничә вариантта тәкъдим ителде. Дәреслектә бирелгән өй эшләре уртача укучыга исәпләнгән.

Дәресләрнең тәрбияви ягына да тиешле игътибар бирелгән. Мөгаллим татар халкының төрле уеннарын, милли бәйрәмнәрен, йолаларын белүне активлаштыра. Бу исә балаларыбызда туган татар халкына ихтирам һәм хөрмәт хисләре тәрбияләү, аларның милләтебез турындагы гомуми белемнәрен тирәнәйтү максатына хезмәт итә.

Методик кулланманың тагын бер игътибарга лаек ягы шунда: ул укучының да, укытучының да иҗади эшләве өчен киң урын калдыра. Һәрбер дәреснең максаты, дәреснең һәр этабының җентекләп язылуы, укучылардан көтелгән җавапларның бирелүе әле яңа гына эшли башлаган яшь укытучыга да бу фәнне укытуда авырлыклар тудырмас.

1 нче дәрес

Тема: Сөйләм кешенең хисләренә тәэсир итә.

Максат: 1. Укучыларга сөйләмнең кеше хисләренә тәэсир итә алу көчен күрсәтү. 2. Аларның сәнгатьле уку һәм сөйләү күнекмәләрен үстерү өстендә эшләү. 3. Әдәпле итеп сөйләшергә өйрәнергә теләк уяту.

Материал: Х. Госман, З. Мәҗитов. «Әдәбият теориясе», Казан, 1980; Г. Ибраһимов. «Алмачуар»; Ф. Яруллин. «Мәктәптән кайтып киләм»; Л. Лерон. «Транзистор үч ала», Казан, 1989.

Дәрес барышы

I. Дәреснең темасы һәм максаты белән таныштыру.

— Сез, укучылар, сөйләмнең нигә кирәк икәнен беләсез инде. Шуларны искә төшереп китик әле.

— Төрле яңалыкларны белү өчен.

— Үзебезнең уйлаганнарны әйтеп бирү өчен.

— Яңа белем бирү өчен.

— Ә бүген без сезнең белән сөйләмнең кеше хисләренә ничек тәэсир иткәнлеге белән танышырбыз.

II. Яңа материал. Дәреслектәге текстларны укып анализ ясау.

1. Ф. Яруллинның «Мәктәптән кайтып киләм» шигыре өстендә эш:

а) шигырьне сәнгатьле итеп уку;

б) сорауларга җавап бирү:

— Шигырьдәге укучы нинди хисләр кичерә дип уйлыйсыз? (Ул бик шатлана.);

— Сезнеңчә, ул малаймы, кызмы? (Малай, чөнки урамда песиләрне, этләрне күбрәк малайлар күзәтеп йөри.);

— Малай нигә сөенә? (Күп итеп «биш»ләләр алганга.)

2. Г. Ибраһимовның «Алмачуар» әсәреннән өзек уку.

а) Сүзлек өстендә эш:

Адәм — кеше

Дөньядан үтте — үлде.

б) Сорауларга җавап бирү.

3. Л. Леронның «Үзем уйнасаммы» дигән хикәясен уку.

4. «Малай һәм Арыслан» әкияте өстендә эш.

а) Укытучының кереш сүзе:

— Әгәр сез сүзләрне дөрес сайласагыз, иң усал кешеләр дә сезне тыңларлар. Ә хәзер «Малай һәм Арыслан» дигән әкият белән танышыйк.

Укытучы үзе сөйли, магнитофоннан тыңлата яки алдан бер укучыга хәзерләнергә тәкъдим итә ала.

б) Сорауларга җавап бирү.

5. Физкультминут: әйтелгән күнегүләрне «зинһар өчен», «рәхим итеп, эшләгезче» дигән сүзләр әйтелгәндә генә эшләргә.

— Зинһар өчен, кулларыгызны өскә күтәрегезче! (Балалар эшлиләр.)

— Кулларыгызны төшерегез! (Күнегүне эшләмиләр.) һ. б.

III. Материалны ныгыту.

1. Тыңлаганда игътибарсызлыкны искәртү.

— Барыгыз да беләсез: сез сөйләгәндә башкалар тыңлап торса гына, сөйләве кызык. Шуңа күрә укытучы сөйләгәндә дә, башкалар сөйләгәндә дә бик игътибарлы булырга кирәк. Сөйләүче сезгә кисәтү ясарлык булмасын. Кисәтүне телдән дә, төрле ишарәләр белән дә ясап була (укытучының туктап калуы, иреннәргә бармакны аркылы кую, күз белән, ишарәләр белән һ. б.). Башка кешенең игътибарын тартмас өчен, сезгә сөйләүче ишарә ясаса, шунда ук сөйләшүдән туктап, тыңлый башларга кирәк.

2. Тел турындагы мәкальләрне анализлау.

IV. Йомгаклау.

Укучылар нәтиҗә ясыйлар: сөйләм төрле яңалыкларны белү, үзебезнең уйлаганны әйтү, яңа белем алу өчен генә түгел, ә кешеләргә тәэсир итү, юату, кисәтү өчен дә файдаланыла.

V. Өй эше.

1. Җәй, каникуллар турында шигырь язгыз яки хикәя төзегез.

2. Музейга (паркка, концертка) бару турында сочинение язып килегез.

2 нче дәрес

Тема: Җанлы сөйләм һәм язганны укып сөйләү.

Максат: 1. Укучыларны җанлы сөйләм һәм язганны укып сөйләү арасындагы охшаш һәм аермалы яклар белән таныштыру. 2. Аларның җанлы сөйләм күнекмәләрен үстерү өстендә эшләү. 3. Бер-берсен тыңлап, хаталарын төзәтә белергә өйрәтү.

Материал: Й. Гәрәйнең «Урман — кешенең якын дусты» хикәясе.

Җиһазлау: магнитофон.

Дәрес барышы

I. Дәреснең темасы, максаты белән таныштыру.

— Сез бүген телдән һәм язма сөйләм белән танышырсыз, моңарчы алган белемнәрегезне тагын да тирәнәйтерсез.

II. Яңа материал өстендә эш.

1. Укытучының сөйләве.

— Укучылар, узган ел без сезнең белән Тукай-Кырлайга музейга барган идек. Анда нәрсәләр күрдек, әйдәгез, искә төшерик әле. (Балаларның җавабы тыңлана.) Ә хәзер Ләйсән анда бару турындагы сочинениесен укыр. (Сочинение тыңлана.) Бу ике сөйләм үрнәге бер-берсеннән аерыламы? Сезгә кайсысы ошады? Ни өчен? (Җаваптан соң.) Әйе, Азат бер җиргә дә язылмаган текстны үзе уйлап сөйләде. Ул уйланып-уйланып та торды, искә төшерә алмыйча тукталды да. Ә Ләйсән алдан язып килгән иншасын тиз-тиз, сәнгатьле итеп укыды. Чөнки инде ул фикерләрен өйдә үк уйлап килгән.

2. Җанлы сөйләм һәм язганны укып сөйләү турында аңлату.

3. Ишеткәнгә анализ ясау.

— Хәзер магнитофон язмасында ике сөйләм үрнәге тыңларбыз. Аның кайсысы җанлы сөйләм, ягъни язылмаганны үзең уйлап сөйләү, ә кайсысы язганны укып сөйләү булыр? (Җаваптан соң.) Ни өчен беренчесен — җанлы сөйләм, ә икенчесен язганны укып сөйләү дип уйлыйсыз?

— Беренчесендә кыз туктап-туктап ала, сүзләрен төзәтә, җөмләләре дә бик төгәл түгел.

— Икенчесендә ул бер дә дә уйланып тормый, укый да укый. Ул аны берничә тапкыр укып та чыккандыр: бик шома укый.

4. Физкультминут төрле хәрәкәтләр белән үткәрелә.

III. Яңа материалны ныгыту.

1. Ситуацияләргә анализ ясау.

— Укучылар, мин сезгә берничә ситуация әйтәм. Игътибар белән тыңлап торыгыз. Кайсын алдан хәзерләнеп, язып уку, кайсысын җанлы сөйләм итеп файдалану уңышлы булыр?

1 нче ситуация: Безнең белән очрашуга сугыш ветераны килде, дип уйлыйк. Ничек уйлыйсыз: ул сөйлисе текстын алдан язып килерме, әллә, җанлы итеп, үзләренең ничек сугышканнары турында сөйләрме? (Җанлы итеп сөйләр.)

2 нче ситуация: Сыйныфта иң яхшы сочинениегә конкурс уздырдыгыз, ди. Иң яхшы сочинениенең эчтәлеген сөйләп чыгу әйбәтрәкме, әллә укып чыгу уңышлыракмы? (Укып чыгу.)

3 нче ситуация: Мәктәптә булган кызыклы вакыйганы әниегезгә язып сөйләрсезме, әллә җанлы сөйләмдәме? (Җанлы сөйләмдә.)

IV. Йомгаклау.

— Без бүген нәрсә турында сөйләштек? (Җавап.)

— Җанлы сөйләм кызыклыракмы, әллә язганны укып сөйләүме? (Урынына карап икесе дә кирәк.)

— Җанлы сөйләм вакытында да үзеңне контрольдә тотарга кирәк, язып куясы түгел әле дип, ямьсез сүзләр кулланып сөйләшергә ярамый.

V. Өй эше.

1. Көзге урманга баруыгыз турында җанлы сөйләмгә һәм язганны укып сөйләүгә мисаллар китерергә.

2. Җәй көне үзегез белән булган бер кызыклы вакыйганы җанлы итеп сөйләгез.

3 нче дәрес

Тема: Әдәби сөйләм.

Максат: 1. Балаларга әдәби тел турында төшенчә бирү. 2. Аның үзенчәлекләрен һәм кулланылышын аңлату. 3. Әдәби телнең матурлыгын сизәргә, тоярга өйрәтү.

Материал: Г. Хәсәнов. «Артыш җиләге»; Р. Хафизова. «Курай-малай һәм Талсылу»; И. Гайфуллин. «Балык тотканда».

Дәрес барышы

I. Дәреснең темасы һәм максаты белән таныштыру.

— Без төрле очракта сөйләмнең төрле төрен файдаланабыз. Өйдә гади сөйләм төрләрен кулланабыз. Иптәшләрегез

белән сөйләшкәндә дә гади сөйләмнән файдаланасыз. Ә дәресләрдә күбрәк фәнни сөйләм кулланабыз.

II. Яңа материал.

1. Әсәрләрдән өзекләрне уку һәм анализлау.
   а) И. Гайфуллин. «Балык тотканда»;
   б) Р. Хафизова. «Курай-малай һәм Талсылу»;
   в) Г. Хәсәнов. «Артыш җиләге».
2. Әдәби сөйләмгә билгеләмә бирү.

— Кешенең әйтергә теләгән фикерен сөйләмдә сүзләр ярдәмендә сурәтләү әдәби сөйләм була. Әгәр әдәби сөйләм куллансак, тыңлаучы да сөйләүче кичергән хисләрне аңларлык булырга тиеш.

3. Сөйләм төрләрен аерып әйтү.

Төрле очракта төрлечә сөйләшәбез:

— Җанлы итеп сөйлибез (гади сөйләм).

— Төгәл итеп хәбәр итәбез (фәнни сөйләм).

— Сүзләр ярдәмендә сурәтлибез (әдәби сөйләм).

4. Ритмик музыка астында физкультминут.

III. Үткәннәрне ныгыту.

1. Хайваннар турында кызыклы хикәяләр төзү.

— Әйдәгез, рәсемнәр күргәзмәсе оештырабыз. Рәсемнәрне сүзләр белән ясыйбыз. Рәссам буяулар белән төсле рәсем ясаган кебек, сүзләр белән дә бик ачык картиналар сурәтләргә була. Яраткан хайваннарыгыз турында кечкенә генә кызыклы хикәяләр уйлап, төзеп карагыз.

2. «Эзләп тап» уены.

Уйнаучылардан берәү икенче бүлмәгә чыгып тора. Калган уенчылар берәр нәрсә исемен сайлап куялар. Чыгып киткән уенчыны чакырып кертәләр һәм ул уйланган нәрсәне белергә тырыша. Ул төрле сораулар бирә:

— Ул нинди?

— Дүрт аяклы.

— Нәрсә ашый?

— Үлән ашый.

— Мөгезе бармы?

— Бар һ. б. сораулар.

Белмәсә, икенче әйбер исемен уйлап табарга тырыша. Белсә, икенче кеше чыгып китә.

IV. Йомгаклау.

— Әдәби сөйләм нинди була?

— Әдәби сөйләмнең билгеләмәсен әйтеп карыйк.

V. Өй эше.

1. Рәссам төсле буяулар белән рәсем ясаган кебек, дәреслектә бирелгән рәсемнәрне сүзләр белән ачык итеп сурәтләгез.

2. Үзегез яраткан хайван рәсемен ясагыз.

Укытучы өчен белешмә

Роза Хафизова

Балалар язучысы Роза Сәет кызы Хафизова 1929 елның 6 февралендә Бөгелмә шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә туган. Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлеген тәмамлагач, Төмән өлкәсе Тубыл шәһәрендәге татар урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты фәннәрен укыта. 1952 елдан башлап күп газета-журналлар редакцияләрендә эшли. 1962 елдан 1986 елга кадәр республика татар балалар журналы «Ялкын»ның баш редакторы була.

Р. Хафизова — үзенең әдәби иҗатын тулысынча балаларга багышлаган язучыларның берсе. Аның нәниләр өчен әкиятләре һәм тәрбияви эчтәлектәге хикәяләре тупланган «Кыңгыраулар җыры» исемле беренче китабы 1967 елда басылып чыга. Бүгенге көндә ул — ике дистәдән артык китап авторы. Аның «Курай-малай маҗаралары», «Кирлемән», «Кашкарыйлар озын гомерле», «Әкиятләр», «Актәпи ник моңая» һ. б. китаплары яшь укучылар арасында популярлык казанды. Аның аерым әсәрләре рус, үзбәк, казакъ, украин һ. б. телләргә тәрҗемә ителгән.

4 нче дәрес

Тема: Киң һәм тар темалар.

Максат: 1. Укучыларның бирелгән тема буенча текст турындагы белемнәрен ныгыту. 2. Практик күнегүләр аша киң һәм тар темалар турында төшенчә бирү. 3. Укучыларның күзәтүчәнлекләрен үстерү.

Материал: Г. Бакир. «Кышкы уен»; Г. Бәширов. «Беренче кар».

Дәрес барышы

I. Дәреснең темасы, максаты белән таныштыру.

— Без бүген сезнең белән киң һәм тар темалар турында сөйләшербез.

II. Яңа тема өстендә эш.

1. Бирелгән темаларга чагыштырма анализ ясау.

Укытучы балалардан: «Кыш» дигән темага сочинение язарга уйласагыз, нәрсә турында язар идегез?» — дип сорый. Балалар үзләренең нәрсә турында язарга уйлаганнарын әйтәләр.

2. Дәреслектә бирелгән рәсемнәргә исем сайлау.

Кыш.

Беренче кар.
Шугалакта.
Без ничек Кар бабай ясадык.
Кар атышып уйнаганда.
Таудан чана шуганда.

3. Киң һәм тар темалар турында төшенчә бирү.

4. Укытучы белән укучылар бергәләп нәтиҗә ясыйлар:

— Кыш көне бик күп нәрсәләр күрергә була. Аларның бөтенесе турында да берьюлы сөйләп бетерү мөмкин түгел. Шуңа күрә үзең күргән яки ишеткән бер вакыйга турында язсаң, мондый иншалар кызыклырак була.

«Кыш» үзе бик киң тема икән, ә без сайлаган темалар тар тема була.

5. Физкультминут: хәрәкәтләр белән «Биек-биек тау битендә» җырын җырлау. Җырның тар темага каравын ачыклау.

III. Ныгыту.

Дәреслек ахырында бирелгән темаларның бүленешенә анализ ясау.

— «Туган ил» китабыгызның «Эчтәлек» дигән өлешен табыгыз әле. Анда киң һәм тар темалар бирелгән. Мәсәлән, «Көз муллык китерә» дигән тема астында бик күп әсәрләр бирелгән. Сез ничек уйлыйсыз, боларның кайсысы киң тема, кайсысы тар тема булыр икән?

Башка темалар да шулай тикшерелә.

Тест.

Тар темаларны дөрес билгелә.

Көз
1. Көзге табигать
2. Хайваннар
3. Көз көне кешеләр хезмәте

Безнең гаилә

1. Безнең өй
2. Яраткан кешеләрем
3. Кунаклар килде

Яраткан шөгылем

1. Безнең сыйныф
2. Түгәрәктә
3. Кул эшләренә өйрәнәбез

Тынычлык өчен көрәш

1. Сугышларны булдырмыйк
2. Балалар сугыш теләми
3. Һәрвакыт булсын кояш

Гөлләр

1. Бүлмә гөлләре
2. Чәчәкләр
3. Гөлләр утыртканда

IV. Өй эше.

1. Бирелгән киң темалардан мөмкин булганча күбрәк тар темалар табыгыз: «Кышкы каникуллар», «Безнең мәктәп», «Безнең табигатебез».

2. Үзегезнең мәктәбегез турында сөйләргә өйрәнегез.

5 нче дәрес

Тема: Бирелгән тема буенча текст чикләре.

Максат: 1. Текстның темасын төгәл итеп ачып бирергә өйрәнү. 2. Текстта кабатлаулар, артык җөмләләр куллануны кисәтү. 3. Текстта җибәрелгән хаталарны табып төзәтергә күнектерү.

Материал: «Уйныйбыз да, җырлыйбыз да», Чаллы, 1991.

Дәрес барышы

I. Дәреснең темасы, максаты белән таныштыру.

II. Яңа материал.

1. Балаларның иншаларын чагыштырып анализлау.

а) «Көзге кырау» дигән 2 текстны уку, анализлау, артык җөмләләрне табу. (Икенче текстта артык җөмләләр бар. Малайның (яки кызның) иртән нәрсәләр эшләгәне белән көзге кырау арасында бернинди дә бәйләнеш юк.);

б) «Кышкы урманда», «Тауда» дигән сочинениеләрдәге өзекләрне төзәтеп язу;

в) Нәтиҗә ясау. Бирелгән һәр текст теманы төгәл ачарга тиеш. Анда артык җөмләләр, сүзләр булмасын. Бер үк сүзне кабатлау да текстны ямьсез һәм аңлаешсыз итә;

г) Тактага язылган текстларны төзәтегез (тактага алдан язып куярга кирәк):

Безнең гаилә.

Безнең гаилә зур. Гаиләдә әти, әни, әби, бабай, абый һәм мин яшибез. Гаиләбез белән без бик тату яшибез. Без барыбыз да әби белән бабайны хөрмәт итәбез.

Кызыклы китап.

Мин китаплар укырга яратам. Минем яраткан китабым — «Шүрәле». Аны яраткан язучым Г. Тукай язган. Г. Тукай язган «Су анасы», «Кәҗә белән Сарык» әкиятләрен яратып укыдым. Кызыклы китаплар укып күп белергә була.

2. Физкультминут.

3. «Шуннан соң ничек?» уены.

Уйнаучылар түгәрәкләнеп утыралар (балалар күп булганда, үз урыннарында калалар). Берәү хикәят сөйли:

— Мин бер заман Һиндстанда сәяхәт итеп йөргәндә, бер юлбарыска очрадым,— дип, хикәясен туктата да, тиз генә берәр кеше алдына барып: «Шуннан соң ничек?» — дип сорый. Ул кеше хикәяне өзелгән җиреннән дәвам иттерергә тиеш. Сөйләп алып киткән кеше тагын хикәясен кинәт кенә бер урында өзә дә, берәр уйнаучы алдына тиз генә баса: «Шуннан соң ничек?» — дип сорый. Соралган кеше бернәрсә дә сөйли алмый тик торса, аңа җәза бирелә.

— Бу уенда барлык җөмләләр дә урынлы кулланылдымы? Ни өчен шулай уйлыйсыз?

4. Тексттагы беренче һәм ахыргы җөмлә.

— Сезнең алдыгызда берничә текст бар. Беренче һәм ахыргы җөмләләргә игътибар бирик әле. Текст кинәт кенә башланып, кисәк кенә беткәнме?

— Юк.

— Текстны яза башлаганда кереш җөмлә кулланыла. *Бу вакыйга кайчан, кайда булган иде? Бу кайсы вакыт?* һ. б. сорауларга җавап бирелә.

— Һәр тексттан беренче җөмләне табыгыз. Алар урынлы кулланылганмы? (Җавaптан соң.) Ә текст ахырында йомгаклап, нәтиҗә ясап, берәр җөмлә языла. Сез ул җөмләләрдә

берәр вакыйгага үзегезнең мөнәсәбәтегезне дә белдерә аласыз: *Миңа ошады* яки *Миңа ошамады* дип, мәсәлән. Текстлардагы соңгы җөмләләрне табыгыз. Алар дөрес кулланылганмы?

III. Ныгыту. Төрле вариантта оештырырга мөмкин.

1 нче вариант. Укытучы язып өләшкән өзекләрдәге хаталарны төзәтү.

2 нче вариант. Укытучы биргән өзекләргә беренче һәм соңгы җөмләләр уйлау.

3 нче вариант. Дәреслектә бирелгән җөмләләрдән бәйләнешле текст төзергә.

Суалчан кунакка бара.

Булган, ди, бер Суалчан. Яңгыр аны кунакка дәшкән. Бик озаклап җыенгач, киткән бу Яңгыр янына кунакка. Бик, би-и-ик, би-и-и-и-ик озак барган, ди. Барган да барган икән. Бер дә ашыкмаган. Бер тамчы да ашыкмаган. Барып җитсә, ни күрсен: Яңгыр моны көтә-көтә Карга әйләнгән. «Кунакка кем янына барсаң да ярый. Кар, син мине кунак ит»,— дигән Суалчан. Ләкин Кар аңа ишеген ачмаган. Суалчан ач килеш үз өенә кайтып киткән. Кунакка вакытында барырга кирәк. Югыйсә көтә-көтә кунакның ашы суынып бетә.

Әхәт Гаффар

IV. Йомгаклау.

— Без бүген дәрестә ниләр эшләдек? Нәрсәләр белеп калдыгыз?

— Текстның темасы төгәл ачылырга тиеш.

— Текстта кабатлаулар, артык җөмләләр булмаска тиеш.

— Текстның беренче һәм соңгы җөмләләренә игътибарлы булырга кирәк.

V. Өй эше.

1. «Яфрак яңгыры» дигән темага кечкенә күләмле сочинение язарга.
2. Үзегезнең яраткан китабыгыз турында сөйләгез.

6 нчы дәрес

Тема: Текстның төп фикерен билгеләү.

Максат: 1. Текст турында төшенчә бирү. 2. Текстның темасы буенча эчтәлеген ачарга тырышу. 3. Укучыларга экологик тәрбия бирү.

Материал: А. Алиш. «Нечкәбил»; Д. Аппакова. «Кечкенә Бануның тарихы», Казан, 1990.

Дәрес барышы

I. Тема һәм максат белән таныштыру.

II. Яңа тема өстендә эш.

1. Текст турында төшенчә бирү:

— Язуда теркәлгән яки басылган сөйләм текст була. Мәсәлән: шигырь тексты, хикәя, көндәлек, әкият тексты. Без язган изложение яки сочинение дә текст була.

2. Алдагы татар теле дәресендә яздырылган изложение яки сочинение тексты укыла.

3. Дәреслектә бирелгән текстны укып анализлау һәм исем кушу.

4. Г. Тукайның «Эш беткәч уйнарга ярый» шигыре анализлана.

5. Укытучы белән берлектә нәтиҗә ясыйлар: төп фикер текстның исемендә, аерым җөмләләрдә, сүзтезмәләрдә һәм сүзләрдә бирелергә мөмкин икән.

6. Музыка тыңлау.

Татар халык биюе көен тыңлау. Соңыннан балаларның күз алларына нәрсәләр килгәне турында сөйләшү үткәрелә.

III. Ныгыту.

1. Текстның исеменә карап, эчтәлеген белергә тырышу.

«Песнәк нигә елаган?»

«Эш беткәч, үкенүдә файда юк».

«Мәңгелек ихтирам аларга».

«Кәҗәләр, кыяр һәм без».

2. Алда бирелгән темаларның берсенә текст яз. Ул әкият, хикәя, шигырь, мәкалә формасында булса да ярый.

IV. Дәрескә йомгак ясау.

— Нинди генә текст алсак та, ул теманы ачарга тиеш. Бигрәк тә сочинение язганда, үзебез сайлаган теманы ачарлык итеп язарга кирәк.

V. Өй эше.

Дәреслектә бирелгән текстны укып төп фикерен билгеләгез, текстка исем кушыгыз.

7 нче дәрес

Тема: Әсәрнең төп фикерен кыскача сөйләү (аннотация).

Максат: 1. Балаларны әсәрнең кыскача эчтәлеге белән таныштырга өйрәтү. 2. Укучыларны аннотация язарга өйрәтү. 3. Эстетик тәрбия бирү.

Материал: Г. Хәсәнов. «Елның дүрт фасылы», Казан, 1991; Г. Мөхәммәтшин. «Без әле җирдә яшибез», Казан, 1982; А. Алишның «Койрыклар» әкияте; укучыларның яраткан китаплары.

Дәрес барышы

I. Дәреснең максаты белән таныштыру.

— Башкалар да син укыган китапны укырга теләсен өчен, китап белән ничек таныштырырга? Хәзер шул хакта сөйләшербез.

II. Яңа материал өстендә эш.

1. Г. Хәсәновның «Елның дүрт фасылы» китабына карата аннотация уку. Бу китапка әдипнең туган ягыбыз табигате, җәнлекләр һәм кошлар дөньясы турында язылган, укучылар тарафыннан яратып каршы алынган әсәрләре тупланган.

2. Г. Мөхәммәтшинның «Без әле җирдә яшибез» әсәренә ике төрле аннотация белән таныштыру.

— Кайсысы укучыны кызыктыра торган итеп язылган?

3. Физкультминут: «Каз талау» күренеше.

4. Класс белән бергәләп, А. Алишның «Койрыклар» әкиятенә аннотация язу.

— Бу әкияттә нәрсәләр турында сөйләнә?

— Урманда хайваннарга койрык өләшү турында.

— Анда нәрсәләр катнаша?

— Саескан, Хәйләкәр төлке, Аю бабай, Кыр куяны, Бүре абзый, Ат, Фил, Дуңгыз.

III. Ныгыту.

— Үзеңә ошаган берәр китапка аннотация яз. (Укытучы, рәсем дәресендә, альбом битен урталай бөкләтеп, укучыларга яраткан китабының тышлыгын ясарга тәкъдим итә һәм аны әзер китапка аннотация яздыру өчен куллана ала. Соңыннан «Минем яраткан китапларым» дигән күргәзмә оештырып була.)

Аннотацияне:

— Язучы бу китапта ... турында сөйли;

— Бу хикәя ... турында;

— Бу хәл ... булган;

— Син ... турында укырга яратасыңмы? — дигән җөмләләр белән башларга мөмкин.

IV. Йомгаклау. Күргәзмә оештыру.

V. Өй эше.

1. Яраткан китабыгызның тышлыгы рәсемен ясап, эченә кызыклы итеп аннотация языгыз.

2. Ел фасылларына багышлап, нәни китапчыклар ясагыз.

3. Үзегезнең язган шигырьләрегезне туплап, кулъязма китап ясагыз.

Укытучы өчен белешмә

Газиз Мөхәммәтшин

Газиз Фазлый улы Мөхәммәтшин 1932 елның 23 декабрендә Минзәлә районы Яңа Бикчәнтәй авылында колхозчы гаиләсендә туа. Башта Минзәлә педагогия училищесын, аннары Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый. Башта Түбән өлкәсендә укытучы була, аннары «Чаян», «Ялкын», «Казан утлары» журналларында эшли. 1960 елда «Сер итеп кенә» исемле беренче китабы басыла. Аның «Яз башы», «Йолдызлар астында», «Торналар киткәндә», «Без әле җирдә яшибез», «Саумысез, аккошлар» һәм башка китаплары бар. Г. Мөхәммәтшин 1972 елның 17 февралендә вафат булды.

8 нче дәрес

Тема: Фикерләү — дәлилләү.

Максат: 1. «Ни өчен?» дигән сорауга аңлатып һәм дәлилләп җавап бирергә өйрәтү. 2. Балаларны, курыкмыйча, үз фикерләрен әйтергә күнектерү. 3. Укучыларның логик фикер йөртүләрен үстерү өстендә эшләү.

Материал: Р. Газизовның «Кем ул?» шигыре; В. Бианкиның «Чәнечкеле ипи» хикәясе; табышмаклар.

Дәрес барышы

I. Тема һәм максат белән таныштыру.

II. Яңа материал өстендә эш.

1. Фикерләү барышында дәлилләргә өйрәнү.

— Рафаил Газизовның «Кем ул?» шигырен укырбыз. Ә сез «Кем ул?» соравына җавап табарга тырышыгыз.

— Бу кем дип уйлыйсыз? Үз фикерегезне дәлилләп күрсәтегез. (Балалар төрлечә әйтә.) Дәлилләгәндә *мин уйлыйм, ә минемчә, миңа шулай тоела* кебек сүзләр кулланырга мөмкин.

2. Әлеге фикернең схемасын төзү.

3. В. Бианки әсәрен укып, фикерне дәлилләү.

— Минемчә, бу ипи булмаган, чөнки икмәк чәнечкеле булмый.

— Минем уйлавымча, аларның ипиләренә чәнечкеле үләннәр ябышкан.

— Мин уйлыйм: бу — керпе булган, чөнки урманда чәнечкеле керпе генә була ала.

4. Физкультминут.

III. Ныгыту.

1. Табышмаклар уку. Җавапларын дәлилләү.

2. «Дөрес җавапны сайла!»

— Кәҗә бәтиләре Бүрене кертерләрме? Ни өчен? Дөрес җавапны табып күрсәтегез.

(Ә мин Бүрене керткәннәр, дип уйлыйм, чөнки бәтиләр бик кечкенә булганнар, уйлый белмәгәннәр.)

IV. Йомгаклау.

— Без бүген нәрсәләр өйрәндек?

— *Ни өчен?* соравына дөрес һәм тулы итеп җавап бирергә.

— Укытучы теләсә кайсы дәрестә *ни өчен?* соравын куйса, сез әнә шулай тутырып, төгәл итеп җавап бирерсез дип ышанам.

V. Өй эше.

1. Сезнеңчә, әдәпле кеше нинди була? Тормыштан мисаллар белән дәлилләп җавап бирегез.

2. Сыйныфыгыздагы кайсы баланы иң әдәпле дип санайсыз? Дәлилләп сөйләгез.

9 нчы дәрес

Тема: Фикерләгәндә берничә дәлилләү куллану.

Максат: 1. Берничә дәлил кулланып фикерләү белән таныштыру. 2. Үз фикереңне мөмкин кадәр тулы итеп әйтергә күнектерү. 3. Укучыларның эзлекле фикер йөртүләрен үстерү өстендә эшләү.

Җиһазлау: Таблица.

Беренчедән — во-первых	Өченчедән — в-третьих
Икенчедән — во-вторых	Тагын — еще

Дәрес барышы

I. Тема һәм максат белән таныштыру.

II. Яңа материал өстендә эш.

1. Фикерләү барышында берничә аңлатма булган очраклар белән танышу. «Яфраклы урманда» дигән текстны уку һәм сорауларга җавап бирү.

— Бу тексттаниләр аңлатыла?

— Ничә сәбәп китерелә?

2. Фикер йөртү күнегүләре.

Сүзлектә бирелгән сүзләрне кертеп аңлатырга:

— Кешеләргә кирпечтән өй салу ошый. Беренчедән, кирпечне кызыл балчык һәм ком да кушып ясыйлар. Ә аларны һәркайда табып була. Икенчедән, андый йортларда кышын җылы була. Җитмәсә, җәен, эссе вакытларда, кирпечтән төзелгән йортларда салкынча һава саклана.

3. Физкультминут үткәрелә.

4. Берничә дәлилләү кулланып фикерләр төзү.

— Ерткыч хайваннарны күпләп юк итү зарарлы. Беренчедән, пошилар күп үрчесә, яшь агачларны ашап бетерәләр. Икенчедән, бүреләр — урман санитарлары.

Икенче сәбәпне тулырак ачып, дәфтәрләренә яздырып кую. (Бүреләр — урман санитарлары. Беренчедән, алар көчсез, авыру хайваннарны ашап, калган җәнлекләрне йогышлы авырулардан саклыйлар. Икенчедән, көчсез хайваннар калмагач, аларның авыру балалары да тумый.)

III. Ныгыту.

1. Табышмак җавабын табу.

— Бу нәрсә? Җавабыгызда берничә дәлилләү кулланыгыз. (Беренчедән, лампочка да кояш кебек якты. Икенчедән, ул өйдә түшәмдә эленеп тора. Өченчедән, ул да кояш кебек нурлар сибә. Җитмәсә, өйне яп-якты итә.)

2. «Хәйрулла» уены уйнау.

— Хәйрулла, Хәйрулла,
Ник елыйсың син болай?
— Мин бит кичә нык егылдым
Һәм елыйм шуның өчен.
— Хәйрулла, Хәйрулла,
Ник елыйсың син бүген?
— Юатучы бар бүген —
Мин елыйм шуның өчен.

— *Хәйрулла нигә елый?* соравына дәлилләп җавап бирегез.

IV. Йомгаклау.

— Фикерләгәндә, сөйләшкәндә берничә дәлил куллану ни өчен кирәк дип уйлыйсыз?

— Тыңлаучыны синең сүзләреңнең дөреслегенә ныграк ышандыру өчен.

V. Өй эше.

1. Өлкәннәрне ни өчен хөрмәтләргә кирәклеге турында берничә дәлил китереп хикәя төзегез.

2. Бер табышмак сайлап алыгыз. Җавабының дөреслеген берничә дәлил китереп исбатлагыз.

10 нчы дәрес

Тема: Фикерләгәндә әсәрдән өземтә куллану.

Максат: 1. Фикерләгәндә өземтә кулланырга өйрәнү. 2. Иншалар язганда өземтәләрдән файдалана белү күнекмәләре булдыру өстендә эшләү. 3. Укучыларны төгәллеккә, пөхтәлеккә өйрәтү.

Материал: И. А. Крылов. «Аккош, Кысла һәм Чуртан»; Ш. Галиев. «Камырша»; Г. Тукай. «Көз»; Ф. Яруллин. «Көзге табын».

Җиһазлау: Магнитофон, И. А. Крыловның «Аккош, Кысла һәм Чуртан» мәсәле яздырылган кассета.

Дәрес барышы

I. Дәреснең максаты белән таныштыру.

— Фикерләгәндә аңлатуыбыз һәм дәлилләвебез ышандырырлык килеп чыксын өчен, әсәрдән өземтә кулланырга өйрәнәбез. Әсәрдән кирәкле өземтәне табу бик җиңел түгел.

II. Яңа материал өстендә эш.

1. И. А. Крыловның «Аккош, Кысла һәм Чуртан» мәсәлен магнитофоннан тыңлау.

— *Аккош, Кысла һәм Чуртан ни өчен йөкне урыныннан кузгата алмыйлар?* дигән сорауга җавап биреп карыйк. Сүзләрегезнең дөреслеген әсәрдән өземтә китереп дәлилләгез.

— Йөкне алар үзара килешеп эшләмәгәнгә күрә урыныннан кузгата алмыйлар. Мәсәлдә бу турыда менә ничек язылган:

Бәлки җиңел булыр иде йөк аларга:
Ләкин Аккош талпынадыр болытларга,
Кысла чигә һаман артка,
Ә Чуртан гел суга тарта.

2. Ш. Галиевнең «Камырша» шигырен уку.

— Ни өчен Тимерша Камыршага әйләнгән? Тиешле өземтәне сайлап алыгыз.

— Кулларын тотып карасак,
Мөмкин түгел танырга —
Эшләмәгәч, Тимершабыз
Әйләнгән ич камырга!

3. Физкультминут: «Күрсәт әле» җырлы уены.

4. Сочинение язганда өземтә куллануны аңлату.

— Сочинение язганда теманы ачу өчен өземтә сайлыйбыз. Ул хикәя формасында да, шигырь формасында да була ала. Мәсәлән, әти-әниләрнең эше турында язганда, түбәндәге өземтәне китерергә була:

Без утырган урындык,
Без уйнаган бу курчак,
Дәфтәр, карандаш, чаңгы,
Кашык, тәлинкә, пычак,
Һәр кадак, такта, һәр өй,
Без ашаган бу ипи —
Бар да хезмәт җимеше,
Әти-әниләр эше.

5. «Яз» темасына сочинение язганда, нинди өземтәләр куллана алыр идегез?

IV. Ныгыту. «Көз» темасына сочинение язу өчен өземтәләр сайлату.

Күрәмсез, дусларым,
Көз килде тышта:
Озак тормас, килер
Ак тунлы кыш та.

Г. Тукай

Әткәм кебек тырыш көз,
Әнкәм кебек юмарт көз.
Көзләр юмарт булганга
Бик бәхетле, бик шат без.

Ф. Яруллин

V. Өй эше.

1. Әби-бабайларыгыздан, әти-әниләрегездән сорап, мәкальләр язып килегез.

1 нче рәт. Хезмәт турында.

2 нче рәт. Туган-тумача турында.

3 нче рәт. Моңа кадәр үзегез ишетмәгән мәкальләрне язып килегез.

2. Өземтәләр кулланып, көз турында сочинение языгыз.

11 нче дәрес

Тема: Фикерләгәндә мәкальләр куллану.

Максат: 1. Фикерләгәндә мәкальләрне урынлы кулланырга өйрәтү. 2. Халык авыз иҗаты әсәрләренә хөрмәт тәрбияләү, кызыксыну уяту. 3. Балаларның фикерләрен төгәлрәк, үткенрәк итү өстендә эшләү.

Материал: «Балалар фольклоры: Мәкальләр». Казан, 1959.

Җиһазлау: Таблица, мәкаль китаплары.

Дәрес барышы

I. Дәреснең темасы, максаты белән таныштыру.

II. Яңа материал өстендә эш.

1. Тактага язылган мәкальләрне уку.

— Тырышкан табар, ташка кадак кагар.

— Җиде кат үлчә, бер кат кис.

— «Укыдым» димә, «белдем» диген.

— Тактага нәрсәләр язылган?

— Мәкальләр.

— Ә мәкальләр нәрсә соң алар?

— Мәкальләрне «олылар сүзе» дип тә әйтәләр.

2. Мәкальгә билгеләмә бирү.

— Сөйләшкәндә сүзгә ямь һәм куәт (көч) бирү өчен, көнкүрештә күп сыналган тәҗрибә һәм дәлил урынына әйтеп йөртелә торган кыска, тирән мәгънәле җөмлә *мәкаль* дип йөртелә. Мәкальләрнең ике вазифасы бар: берсе сүзгә ямь бирә, икенчесе куәт өсти. Куәт булгач, димәк, анда кешене сүзгә ышандырырлык көч тә була.

Мәкальләрне урынлы куллана белергә кирәк.

3. Өй эшен тикшерү. Укучыларның язып килгән мәкальләрен укыту һәм аларны ничек аңлауларын ачыклау.

4. Дәреслектәге рәсемнәргә мәкальләр уйларга.

5. Бирелгән мәкальләргә рәсем ясарга.

6. Физкультттәнәфес.

7. Төрле ситуацияләргә мәкальләр сайлау.

Мәсәлән: а) Бер малай, алдан шапырынып йөреп тә, эшен булдыра алмыйча көлкегә калган. Бу малайны гаепләүче һәм яклаучы буларак, мәкальләр сайлагыз.

— Алдан кычкырган күкенең башы авырта.

— Дүрт аяклы ат та сөртенә.

б) Уйламыйча сөйләсәң, авыр хәлдә калырсың.

— Теле йомшак аш ашар,
Теле каты камчы ашар.

— Теле кызганда әйткәннең соңыннан йөзе кызарыр.

— Теле кычыткан сүз бозар, кулы кычыткан эш бозар.

III. Ныгыту.

1. Дәреслектәге мәкальләрне укып, мәгънәләрен аңлату.
2. Уен-ярыш «Кем күбрәк мәкаль белә?»

IV. Йомгаклау. Сочинениеләр язганда, сөйләшкәндә мәкальләр куллану сөйләмне җыйнак, үткен итә, аның куәтен арттыра.

V. Өй эше.

Хезмәт турында сочинение язганда нинди мәкальләр кулланырга мөмкин? Мәкальләр кулланып, хезмәт турында сочинение языгыз.

12 нче дәрес

Тема: Фикерләгәндә нәтиҗә ясау.

Максат: 1. Фикерләүдән чыгып нәтиҗә ясарга өйрәтү. 2. Укучыларның логик фикерләүләрен үстерү өстендә эшләү. 3. Бер үк фикерне берничә төрле итеп әйтергә мөмкин булганлыгын күрсәтү, аны практикада кулланырга өйрәтү.

Материал: Г. Хәсәнов. «Елның дүрт фасылы». Казан, 1991; «Раушан көзге». Казан, 1993.

Дәрес барышы

I. Дәреснең максаты белән таныштыру.

II. Яңа материал өстендә эш.

1. *Ни өчен кара карга белән сыерчыкны күчмә кошлар дип атыйлар?* дигән сорауга җавап бирегез. (Балалар җавабыннан соң.) Җавапның схемасын да төзибез.

2. Яңа схема буенча фикерләүне үзгәртү.

(Бака баласының башы белән койрыгы гына булган, шунлыктан аны Чукмарбаш дип йөрткәннәр.)

Дәреслектәге һәм укучылар үзгәртеп төзегән җөмләне дәфтәрләренә яздырып кую һәм схемаларын карау.

3. Фикерләүнең өлешләрен табу.

— Гөмбә ул үзенчә: чәчәксез һәм яфраксыз үсә, тамырдан үрчи. Без аны йолкып алмыйбыз, төбеннән кисеп кенә алабыз.

Аңлату өлеше:

Гөмбә ул үзенчә: чәчәксез һәм яфраксыз үсә, тамырдан үрчи.

Шунлыктан:

Нәтиҗә: Без аны йолкып алмыйбыз, төбеннән кисеп кенә алабыз.

4. Бер үк текстны ике төрле итеп үзгәртү.

— Куяннар яз көне урманны ташлап китәләр, чөнки аларның ак туннары еракган күренеп тора.

— Елга тирәләре язын куян кебек ала-кола була, шунлыктан куяннар урманны ташлап елга буйларына китәләр.

5. Физкультминут.

III. Ныгыту.

1. Г. Тукайның «Бу кайсы вакыт?» дигән шигырен укып, сорауга җавап бирү.

2. Ф. Шәфигуллинның «Исемең Ләйсән булыр» хикәясеннән өзекне укып анализлау.

— Курчак, күзәтүләреннән чыгып, нинди нәтиҗә ясаган?

IV. Йомгаклау.

— Нәтиҗә ясау өчен ни кирәк?

V. Өй эше.

«Иренгән ике эшләр» дигән мәзәкне укып, нәтиҗә ясарга.

13 нче дәрес

Тема: Кагыйдәләр иленә уен-сәяхәт.

Максат: 1. Укучыларны кагыйдә кулланып аңлату белән таныштыру. 2. Төрле фәннәр буенча алган белемнәрен ныгыту. 3. Фәннәрне тагын да ныграк үзләштерергә теләк уяту.

Җиһазлау: 1) Укытучы нинди тукталышлар алуны кирәк дип саный, шуларны күрсәткән таблица-карта:

1. Җыелу урыны «Ни өчен?»
↓
2. «Баш хәрефләр иле»
↓
3. «Табигать кочагында»
↓
4. «Тапкырлар иле»
↓
5. Йомгаклау. «Чөнки» тукталышы

2) Флаг (өч төскә буяла, сүзләре языла)

Аңлатыла торган фикер
чөнки
кагыйдә

3) Мисаллар язылган индивидуаль карточкалар

Дәрес барышы

I. Кыңгырау шалтырауга, укытучы сыйныф каршына баса. («Ни өчен?» исемле җыелу урыны.)

— Без бүген сезнең белән уен-сәяхәткә чыгарбыз. Барыбыз да җыелып беттекме? Утырыгыз. Безнең җыелу урыныбыз «Ни өчен?» дип атала. Без кайсы гына тукталышка туктасак та, «Ни өчен?» дигән сорауга җавап бирербез.

Безнең флагыбыз өч төстән тора.

— Зәңгәренә нәрсә дип язылган?

— «Аңлатыла торган фикер».

— Сарысына нинди сүз язылган?

— «Чөнки» сүзе.

— Ә кызылына?

— «Кагыйдә» дип язылган.

— Бүген җавап биргәндә, шушы схемадан файдаланырбыз. Шуңа күрә флагны үзебез белән алабыз. (Алдан хезмәт яки рәсем дәресендә бу флагны ясатып куеп, хәзер аңа тиешле сүзләрне яздырып, һәр балага үз флагы юлга талисман итеп алдырыла.)

— Әйдәгез, карта белән танышыйк.

— Ә хәзер китү өчен транспорт төрен сайлыйк (ат, машина, поезд һ. б. сайлана ала).

— Мин атны сайлыйм, чөнки ул табигатькә зыян китерми.

— Мин поездны сайлыйм, чөнки ул тизрәк бара.

— Мин автобусны сайларга тәкъдим итәм, чөнки анда җырлап барырга җайлы.

Укучылар, «Кәрия-Зәкәрия» җырын җырлап, «Баш хәрефләр иле»нә килеп җитәләр.

II. «Баш хәрефләр иле»ндә.

— Бу утрауга керү өчен, һәр бала баш хәрефтән башланган бер сүз уйлап әйтергә тиеш.

— Казан, Алсу, Караборын, Шушма, Тукай һ. б.

Башка балалар бу сүзләрнең ни өчен баш хәрефтән язылганын аңлатырга тиешләр. Укытучы, балалар әйткәндә, шәһәр исемнәрен әйтүчеләрне — бер урынга, кеше исемнәрен һ. б. әйтүчеләрне икенче урынга утырта бара.

— Мәскәү, Казан, Уфа — шәһәрләр. *Мәскәү, Казан, Уфа* баш хәреф белән языла, чөнки алар — шәһәр исемнәре.

— *Гарифуллин, Исхакова* баш хәреф белән языла, чөнки алар — фамилияләр.

— Тагын нинди сүзләр баш хәреф белән языла?

— Хайван кушаматлары.

— Ил исемнәре.

— Елга, күл исемнәре һ. б.

(Укытучы дөрес җавап биргәннәргә бүләк итеп ясалган «5»ле билгесе бирә ала.)

Нәтиҗә ясау.

Һәр бала аерым-аерым әйтә:

— Кеше исемнәре,

— Фамилияләр,

— Хайван кушаматлары һ. б.

Хор белән:

— Баш хәреф белән языла.

III. Ә хәзер «Табигать кочагында» тукталышына барырбыз. Юлыбыз кыска булсын өчен, мин сезгә бер хикәя укырмын. Ә тукталышка килеп җиткәч, сорауларга җавап бирербез.

Гыйльмия Таһированың дәреслектәге «Кечкенә миләш» хикәясе укыла. Сорауларга җавап.

— Беренче флаг-схемага карап җавап бирик.

— Нарат, каен, усак — агачлар, чөнки аларның бер генә кәүсәләре бар.

— Гөлҗимеш, чикләвек — куаклар, чөнки алар агачлардан тәбәнәгрәк һәм кәүсәләре дә бер генә түгел.

— Сез урман турында нинди кагыйдәләр беләсез?

— Кырмыска ояларын туздырырга ярамый, чөнки алар, зарарлы бөҗәкләрне ашап, безгә файда китерәләр.

— Гөмбәләрне кисеп кенә җыярга кирәк, чөнки без аларның тамырдан үрчегәннәрен беләбез.

(Монда да күп белүчеләргә төрле рәсемнәр яки «5»леләр бүләк итәргә мөмкин.)

— Бер җирне дә пычратмыйча, туктаган килеш, «Ябалак» уены уйнап алыйк.

Уйнаучылар, кулга-кул тотынып, бер түгәрәк ясыйлар. Берәресе кош тотучы булып уртага чыга. Түгәрәктәгеләрнең кайсы нинди кош тавышына охшатып кычкыра белсә, шул кош исеме белән атала.

Кош тотучы, төрле кош исемнәре катнаштырып, аларга берәр хикәя сөйли башлый.

— Кош балалары! Сезгә бер хәл сөйлим әле. Бүген йортта тавык үз чебиләре белән йөри иде, саескан очты, карга очты, әллә каян козгын төште, бер чебешне тилгән алып китте, аны карчыга тотты, әтәч кычкырып калды! Күгәрчен!

Кош тотучы шулай сөйләп торган арада нинди кошның исемен телгә алса, шул кош исеме белән аталган уенчы тиз генә кычкырып тавыш бирә. Кош тотучы сүз арасында «ябалак» дисә, кошларның барысы да, кулларын җәеп, читкә кача башлыйлар. Кош тотучы аларны куа. Кемне тотса, шул кош тотучы була.

IV. «Тапкырлар иле».

Анда керү өчен малайлар — кызларга, кызлар малайларга табышмак әйтәләр, җавапларын табалар.

Укытучы аларга керү билеты итеп индивидуаль карточкалар бирә ала, балалар җавапларын кагыйдә ярдәмендә аңлаталар.

— Кәҗәгә 7 яшь тулгач, нишли?

— 8 нче китә.

— 1 кг тимер авырмы, мамыкмы?

— Тигез.

— 1994 елда иң зур эшләпәне кем кигән?

— Кемнең башы зур — шул.

— Су кайда коры була?

— Картада.

— Ач карынга ничә йомырка ашап була?

— Берне. (Берне ашагач, карыным ач дип әйтеп булмый.)

— Кем ике тапкыр туа?

— Чебеш.

V. Йомгаклау тукталышы («Чөнки»).

— Балалар, табышмаклар әйтешеп килә-килә сизми дә калганбыз — соңгы тукталышка килеп тә җиткәнбез. Исеме нигә «Чөнки» дип атала микән?

— Чөнки без аңлатыла торган фикер һәм кагыйдә арасында гел *чөнки* сүзен кулландык.

— Әйдәгез, җавап биреп карагыз әле, ни өчен *акбаш* сүзе кушылып языла?

— Чөнки ул — кушма сүз.

— Җавап биргәндә, «без беләбез», «кагыйдә буенча», «кагыйдәдә әйтелгәнчә» сүзләрен дә кулланырга була.

VI. Нәтиҗә ясау.

— Бүгенге сәяхәт сезгә ошадымы? (Балалар җавабыннан соң.)

— Без нинди тукталышларда булдык? (Җавап.)

— Кагыйдә кулланганда шуны онытмаска кирәк: кагыйдә бөтен кеше өчен языла.

VII. Өй эше.

1. «Гөл» сүзе кергән кеше исемнәре язарга.

2. «Ак», «бер» сүзләре белән кем күбрәк сүз төзи ала?

14 нче дәрес

Тема: Котлаулар.

Максат: 1. Укучыларны дөрес итеп котлау текстлары төзергә өйрәтү. 2. Сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү өстендә эшләү. 3. Укучыларны тиешле урыннарда комплиментлар кулланырга өйрәтү.

Материал: А. Милн. «Винни-Пух маҗаралары». Казан, 1991; Р. Вәлиева. «Рәхмәт әйтәсем килә»; Э. Шәрифуллина. «Бүләк әзерләгәндә».

Дәрес барышы

I. Дәреснең темасы һәм максаты белән таныштыру.

II. Яңа материал өстендә эш.

1. Кереш әңгәмә.

— Сез нинди бәйрәмнәр беләсез? Сезне нинди бәйрәм белән котлаганнары бар? Бу бәйрәмдә сезгә нинди теләкләр теләделәр?

2. Дәреслектәге ике котлау текстын чагыштыру.

— Кайсы текст сиңа күбрәк ошады һәм ни өчен?

3. Мөстәкыйль эш. Яңа ел белән котлап, туганнарыгызга открытка языгыз, дәреслектәге схема-таблицадан файдаланыгыз.

4. «Ак калач яки коймаклар» уены.

Балалар, кулга-кул тотынышып, бер түгәрәк ясыйлар. Берсе уртага чыгып баса. Түгәрәктәге балалар, җырлый-җырлый, коймакның ничек пешүен, җәелү-кысылуларын хәрәкәтләр белән күрсәтеп, уртадагы баланы «кысып» куялар. Ул бала үз урынына берәүне сайлап чыгара да үзе түгәрәктәгеләргә кушыла.

Уенның җыры:

Булатның туган көненә
Без пешердек ак калач,—
Менә шулай ул биек,
Менә шулай тәбәнәк,
Менә шуның киңлеге,
Менә шуның тарлыгы,
Ак калач, ак калач,
Теләгәнеңне сайлап кач!

5. Ә. Шәрифуллинаның «Бүләк әзерләгәндә» дигән шигырен уку. Комплиментлар әйтү турында сөйләшү.

— Ә сез әниләрегезне бәйрәм белән ничек котлыйсыз? Котлаганда матур сүзләр — комплиментлар әйтергә дә онытмыйсызмы? Мәсәлән: *Әнием, син бүген бигрәк тә чибәр! Әнием, яңа күлмәгең сиңа бигрәк килешә икән! Әни, коймакларың бигрәк тәмле булган! (Син пешергән коймакларны бигрәк яратам.)*

Комплиментлар кешенең күңелен тагын да күтәреп җибәрәләр. Андый җылы, матур сүзләрне дусларыгызга, туганнарыгызга да әйтергә мөмкин.

III. Ныгыту.

Р. Вәлиеваның «Рәхмәт әйтәсем килә» шигырен сәнгатьле итеп уку, куелган сорауларга җавап бирү.

IV. Йомгаклау.

— Без сезнең белән нәрсәләр өйрәндек? (Җавап.) Котлаганда, бүләкләр тапшырганда нинди сүзләр әйтергә мөмкин? (Җавап.) Алар ни өчен кирәк?

V. Өй эше.

Дустыгызга нинди комплимент сүзләре әйтер идегез, дәфтәрегезгә языгыз.

15 нче дәрес

Тема: Котлау тексты төзү.

Максат: 1. Котлау текстлары төзү буенча укучылар алган белемнәрне ныгыту. 2. Котлауларның нинди өлешләрдән торулары белән таныштыру. 3. Әти-әнине, дусларны ярата белүнең зур бәхет икәнлегенә инандыру.

Материал: Р. Корбанның «Туган көн бүләге»; Г. Зәйнашеваның «Җырлыйм әнием турында» шигырьләре.

Дәрес барышы

I. Котлаулар турында өйрәнелгән материалны ныгыту.

— Котлаулар ничә өлештән төзелә? (Җаваптан соң.) Котлауларны нинди сүзләр белән башлыйбыз?

II. Яңа материал.

1. Котлау текстларына анализ ясау.

а) Хөрмәтле Алсу Илсуровна!

Сезне чын күңелебездән Укытучылар көне белән котлыйбыз. Безгә биргән белемегез һәм күңел җылыгыз өчен Сезгә

зур рәхмәт. Без Сез өйрәткәнчә гадел, намуслы кешеләр булып үсәргә тырышырбыз. Һәрвакыт сәламәт, шат күңелле һәм бәхетле булыгыз.

Сезнең укучыларгыз. 1 нче октябрь, 2002 ел.

б) Котлау сүзләреннән рәхмәт сүзләрен, теләкләрне, укучыларның вәгъдә сүзләрен табыгыз.

в) Котлауның өч өлештән торуын аңлату.

1 нче өлеш — котлауның кемгә багышлануы.

2 нче өлеш — бәйрәм белән котлау.

3 нче өлеш — теләкләр теләү.

2. «Кайсын кайчан» дигән уенны бергәләп уйнау.

3. Котлау тексты төзү.

— Хәзер дәреслектәге котлау текстларын дөресләп төзербез.

4. Котлау текстын язу өчен открытка сайларга өйрәтү (бәйрәм открыткаларын укытучы үзе алып килә яки укучыларга алып килергә куша).

5. Котлаганда телеграммалар русча җибәрелә. Татарстанда исә татарча да җибәреп була.

6. Р. Корбанның «Туган көн бүләге» шигырен уку, «Ни өчен малай бүләкне ошатмаган?» соравына җавап эзләү.

7. Г. Зәйнашеваның «Җырлыйм әнием турында» исемле җырын башкару.

III. Йомгаклау.

Котлаулар эндәш сүздән, тәбрикләүләрдән һәм теләкләрдән тора. Котлаулар чын күңелдән булырга, җылы сүзләрдән торырга тиеш.

IV. Өй эше.

1. Иң якын дустыгызны туган көне белән тәбрикләп, котлау языгыз.

2. Әти-әниләрегез белән берлектә телеграмма бланкасына котлау тексты языгыз.

Укытучы өчен белешмә

Гөлшат Зәйнашева

Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елда Татарстанның Сарман районы Иске Теләнче авылында туа. Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый. Шагыйрәнең җырлары халык арасында киң популярлык казанды. Ул шулай ук драматургия, проза өлкәсендә дә эшли. Дистәләрчә китап авторы.

16 нчы дәрес

Тема. Кунакка ничек чакыралар?

Максат. 1. Укучыларны ягымлы итеп кунакка чакыру үзенчәлекләре белән таныштыру. 2. Кешеләр белән иркен аралашу күнекмәләре булдыру өстендә эшләү. 3. Әхлак тәрбиясе бирү.

Материал: М. Җәлил, Р. Корбан шигырьләре; Р. Мингалимнең «Кунак»; Р. Миңнуллинның «Кунакка килегез» шигыре.

Дәрес барышы

I. Дәреснең максаты белән таныштыру.

— Сез кунакка йөрергә яратасызмы? (Җаваптан соң.) Сезне кем чакыра? (Җаваптан соң.) Чакырганда нинди сүзләр әйтәләр?

II. Яңа материал.

1. Әдәпле итеп чакырырга өйрәтү.

— Без чакыруны нинди сүзләр белән башлыйбыз? (Мин сезне ... чакырам. Рәхим итеп безгә ... килегезче.)

— Кешеләрне каядыр, нәрсәгәдер чакырган вакытта, чакыруның сәбәбен әйтергә кирәк. Ул сәбәпләр күптөрле булырга мөмкин. Мәсәлән:

Туган көн бәйрәменә
Чәй эчәргә
Яңа ел бәйрәменә — килегез.
Шахмат уйнарга
Альбом карарга
Сөйләшеп утырыр өчен

— Чакырганда вакытын әйтеп чакырырга кирәк.

2. Төрле әсәрләрдән өзекләр уку, чакыруның төрләрен һәм максатларын ачыклау (М. Җәлил һәм Р. Корбан шигырьләре өстендә эш).

3. Төрле ситуацияләрне уйнап карау.

— Сез Яңа ел бәйрәменә дусларыгызны ничек чакырасыз? Алар сезгә килергә теләсен өчен нәрсә әйтерсез? (Җаваплар.)

— Сезнең дустыгыз өйдә генә торырга ярата. Сез аны футбол уйнарга чакырырга телисез. Аны сез чакырган урынга барырга ризалатырга тырышыгыз.

4. Дәреслектә бирелгән рәсем буенча хикәя төзү.

5. Физкультминут. «Крокодил Гена» җырын җырлау.

6. Р. Мингалимнең «Кунак» шигырен уку.

Шигырьне алдан хәзерләнгән укучы яисә укытучы үзе сәнгатьле итеп укый.

Сораулар буенча эчтәлекне ачыклау.

III. Йомгаклау. Р. Миңнуллинның «Кунакка килегез!» шигырен уку яки магнитофоннан тыңлау.

Шигырьне уку алдыннан Р. Миңнуллинның биографиясе һәм иҗаты искә төшерелә.

IV. Өй эше.

1. «Кунакка килегез» шигырен яттан өйрәнегез.
2. Туганнарыгызны Яңа ел бәйрәменә чакырып хат языгыз.

17 нче дәрес

Тема: Кунаклар белән үзеңне ничек тотарга?

Максат: 1. Укучыларны кунаклар белән үз-үзләрен ягымлы тотарга өйрәтү. 2. Аларны милли аш исемнәре белән киңрәк таныштыру. 3. Кунакчыллык, киң күңеллелек хисләре тәрбияләү өстендә эшләү.

Материал: Ш. Галиевнең «Кунаклар»; Р. Харисның «Матур өй» шигырьләре, мәкальләр.

Дәрес барышы

I. Дәреснең максаты белән таныштыру.

— Кемне дә булса кунакка чакырганда, нинди сүзләр белән башлыйбыз?

1. «Торна һәм Төлке» әкиятен искә төшерү һәм анализлау.
2. Рәсем буенча әкиятнең эчтәлеген сөйләү.
3. Торна һәм Төлкене кунакка матур итеп чакыру төзү.

II. Яңа материал.

1. Кунак чакыру кагыйдәләре белән таныштыру.

— Кунак чакыруның үз кагыйдәләре бар. Һәр кеше кечкенәдән үк кунак чакыра, кунакларны кабул итә һәм аларның күңелен күрә белергә тиеш. Кунакларга тәкъдим ителә торган уеннар төрлечә булырга — алар белән башваткычлар, шарадалар чишәргә, өстәл уеннары уйнарга, фокуслар күрсәтергә мөмкин. Концерт номерлары да эшләргә була.

2. Ш. Галиевнең «Кунаклар» шигырен уку. Сораулар буенча эчтәлекне ачыклау.

— Кунакларны нинди ризыклар белән сыйлаганнар? (Җавап.) Нинди милли ризыклар пешергәннәр? (Җавап.) Аларны нинди сүзләр белән кыстаганнар? (Җавап.)

3. Р. Харисның «Матур өй» шигыреннән өзек уку. Сорауларга җавап алу. Шагыйрьнең биографиясе белән таныштыру. Сүзлек өстендә эш (бавырсак, урама, гөбәдия, кәләвә, әлбә).

4. Татар халкының милли ашлары турында сөйләшү (милли ризыклардан күргәзмә оештыру да отышлы булыр иде).

5. Мәкальләр уку.

— Ачык йөз — нур өстенә нур.

— Күңелең киң булса, өем тар дип курыкма.

Киң күңеллелек, кунакчыллык турында белгән мәкальләрне искә төшерү. Мәсәлән: «Кунак булсаң, тыйнак бул».

6. Төрле ситуацияләрне уйнап карау.

7. Л. Гангнусның «Әдәплелек әлифбасы» китабыннан өзек уку (37 нче бит).

8. «Ак калач яки коймаклар» уены.

III. Йомгаклау.

Кунак сыйлау такмакларын анализларга мөмкин.

«Кайсы артык» уены.

1. Гөбәдия, бәлеш, пилмән.
2. Бәрәңге, коймак, белен.
3. Компот, кесәл, чәй, аш.
4. Салфетка, чәнечке, кашык, пычак.
5. Бәлеш, салат, өчпочмак.

IV. Өй эше.

1. Кунак сыйлау такмакларын табып, дәфтәрләргә язарга.
2. Аш пешерүче һөнәре турынданиләр беләсез? Шул турыда эзлекле итеп сөйләргә өйрәнегез.

Укытучы өчен белешмә

Ренат Харис

Шагыйрь, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Ренат Харис (Харисов Ренат Мәгъсүм улы) 1941 елның 6 маенда Ульян өлкәсенең Богдашкино районы Зирекле Күл авылында туган. Әти-әнисе укытучылар булып, бер авылдан икенче авылга еш күчеп йөргәнлектән, Ренатның бала чагы һәм мәктәп еллары Буа төбәгендәге авылларда уза. Ренат Мәгъсүм улы, Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлаганнан соң, Арча педагогия училищесында укыта башлый. Соңрак төрле газета-

журнал редакцияләрендә эшли. Хәзерге көндә ул — татар телендә һәм русча тәрҗемәдә дөнья күргән өч дистәдән артык китап авторы.

18 нче дәрес

Тема: План төзү.

Максат: 1. Укучыларны әсәрнең планын төзергә өйрәтү. 2. План буенча текстны сөйли белү күнекмәләрен үстерү өстендә эшләү. 3. Укучыларны юморны аңлый һәм сөйләмдә куллана белергә өйрәтү.

Материал: Л. Леронның «Инша»; Р. Гыйззәтуллинның «Оныгы әбисен ничек кунак итте» хикәяләре.

Җиһазлау: Кыш турында картина, рәсемнәр.

Дәрес барышы

I. Өй эшен тикшерү. Аш пешерүче һөнәре турында сөйләшү.

II. Яңа материал.

1. Л. Леронның «Инша» хикәясен уку һәм эчтәлеген сөйләргә тәкъдим итү.

— Рәфинәнең кем булырга теләгәнен, урыннарын алмаштырмыйча, барыгыз да сөйли аласызмы? (Җаваптан соң.) Ә мин тактага түбәндәге планны язып куйсам? (План ачыла.)

1) Инша язарга бирделәр.
2) Мин икмәк пешерүче булам.
3) Иң әйбәт һөнәр — тәрбияче.
4) Укытучы — мактаулы эш.

План буенча эчтәлек сөйләтү күнегүләре.

2. Планның нигә кирәк булуы һәм әсәрне эчтәлеге буенча өлешләргә бүлү турында сөйләшү. Кайбер план күбрәк эчтәлекне үз эченә ала, ә кайберсе 1—2 җөмләне генә.

3. Р. Гыйззәтуллинның «Оныгы әбисен ничек кунак итте» хикәясен уку һәм бергәләп өлешләргә бүлү, план төзү.

1) Хөсниҗамал әби кунакка килде.
2) Күчтәнәчләр белән сыйлану.
3) Хөсниҗамал әби — капкачы.
4) Урамда.
5) Онык кибетләрне күрсәтте.
6) Хөсниҗамал әби авылга ашыкты.

План язганда берничә төрле вариант уйлап, иң яхшысын сайлап язарга киңәш бирү.

4. Кышка багышланган картинаны карау. Нәрсәләр турында сөйләргә мөмкин булганлыгын ачыклау.

III. Йомгаклау. Картина буенча хикәя төзү (дәреслектә бирелә).

1. Картинаны карау.
2. Сораулар буенча эчтәлекне ачыклау.

IV. Өй эше.

1. Картина буенча план төзегез.
2. План буенча хикәя төзеп сөйләгез.

19 нчы дәрес

Тема: План буенча сочинение язу.

Максат: 1. Укучыларны бирелгән план буенча сочинение язарга өйрәтү. 2. Бәйләнешле сөйләм үстерү өстендә эшләү. 3. Кышның матурлыгын күрергә һәм сурәтләргә өйрәтү.

Материал: Г. Тукайның «Җир йокысы»; Р. Миңнуллинның «Ак кыш»; Г. Ибраһимовның «Кар ява» шигырьләре.

Җиһазлау: Кыш турында өземтәләр сайлау өчен шигырь, хикәя китаплары.

Дәрес барышы

I. Бүгенге дәреснең темасын һәм максатын аңлату.

1. План төрле вариантта булырга мөмкин. Дәреслектә бирелгән үрнәк планнарны карау.

2. Һәр вариант буенча телдән хикәя төзү.

3. Укучыларның өйдә язып килгән планнарын укыту. Бергәләп хаталарын төзәтү. Хикәя төзеп сөйләп карау.

II. Яңа материал.

1. Сочинение язу өчен өземтәләр сайлату. Мәсәлән:

Кырга ак кардан
Юрган ябылган,
Җир язга чаклы
Йокыга талган.

Г. Тукай

Куяннар да ак тун кигән,
Каеннар да ак туннан.
Бүреккә дә, керфеккә дә,
Борынга да ак кунган.

Р. Миңнуллин

Агачларның ботаклары яңа, йомшак ак мамыкларга төренде. Калын-калын болытлар, үз авырлыкларын үзләре күтәрә алмыйча, түбәнгә таба салына башладылар. Зур елгалар әллә кая төпкә — боз астына качтылар.

Г. Ибраһимов

2. Мөстәкыйль рәвештә сочинение язу.

III. Йомгаклау.

IV. Өй эше.

1. Туган тел турында мәкальләр, табышмаклар алып килергә.

2. Туган тел турында өйрәнгән шигырьләрне искә төшерергә, яңаларын өйрәнеп килергә.

20 нче дәрес

Тема: Туган телем — иркә гөлем.

Максат: 1. Укучыларыбызны туган телебезнең байлыгы белән таныштыру. 2. Тел байлыгыннан дөрес файдаланырга өйрәтү. 3. Туган телең белән горурлану хисләре тәрбияләү.

Материал: Г. Тукайның «Туган тел»; Ш. Маннурның «Татарча да яхшы бел» шигырьләре; «Татар халык табышмаклары». Казан, 1970.

Дәрес барышы

I. Сәламләү һәм балаларның белемнәрен актуальләштерү.

1. — Исәнмесез, укучылар!
— Исәнмесез, саумысез!
— Хәерле көн, балалар!
— Көнегез имин үтсен!
— Кәефләрегез ничек соң?
— Кояшлы иртә кебек,
Тукай телен, анам телен
Өйрәнергә дип килдек!

2. Әйдәгез, Г. Тукай сүзләренә җырлана торган «Туган тел» җырын искә төшерик.

3. Сез туган телебез турында нинди мәкальләр беләсез соң?

— Иле барның теле бар,
Теле барның юлы бар. һ. б.

— Бик яхшы, балалар. Ә хәзер дәреслектә бирелгән мәкальләрне укып карыйк. Мәгънәләрен ачыкларга тырышыйк.

4. Ә хәзер мин әйткән табышмакның җавабын эзләп карыйк (табышмак дәреслектә дә бирелгән).

5. Туган телебез турында шигырьләр очратканыгыз бармы?

Ш. Маннурның «Яхшы бел» шигыре өстендә эш:

а) шигырьне сәнгатьле уку күнегүләре;

б) Ш. Маннур иҗаты турында укытучы сөйләве;

в) шигырьнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап:

— Автор безгә нәрсә турында хәбәр итә? (Җавап.) Сезнең туган телегез нинди? (Җавап.) Татар теле турында ниләр беләсез? Шул турыда сөйләгез.

II. Дәреснең темасы, максаты белән таныштыру.

— Әйе, балалар, туган телебез турында нинди генә шигырьләр, мәкальләр, әйтемнәр, җырлар юк. Безнең туган телебез — бик борынгы һәм бай телләрнең берсе. Бүгенге дәрестә без аның байлыгы, тирәнлеге турында сөйләшербез.

III. Яңа материал.

1. Укытучының телебезнең байлыгы турында сөйләве:

— Тел — кешелек дөньясында зур байлык һәм олы хәзинә ул.

Телдә сүзләр бик күп, әмма аларны урынлы итеп файдалана белергә кирәк.

Безнең сөйләмебез — җөмләләрдән, ә җөмләләр сүзләрдән тора. Сүз бер генә аваздан да (*у, и, ә*), берничә аваздан да торырга мөмкин. Әмма теләсә нинди авазлар төркеме сүз була алмый, сүз мәгънә белдерергә тиеш.

Билгеле бер телдәге сүзләр җыелмасы шул телнең лексикасы, тел байлыгы була.

Кайбер сүзләр бер генә мәгънә белдерәләр. Мәсәлән: *китап, дәфтәр, кеше*. Ә кайберләре берничә мәгънә белдерәләр. Мәсәлән:

алма — бит алмасы; бәрәңге алмасы

йөз — кеше йөзе; сан; фигыль

2. Физкультминут.

Хәрәкәтләр һәм төрле авазлар чыгарып, укытучы әйткән хайван, кошларны күрсәтү. Мәсәлән: куян, әтәч, эт, сыер һ. б.

3. Гамәли эшләр.

1) Боларның кайсысы сүз һәм ни өчен? (Һәр балага индивидуаль карточкалар рәвешендә дә бирергә була.)

2) Сүзләрдән җөмләләр төзергә кушу.

3) Өләшенгән рәсемнәр буенча хикәяләр төзергә тәкъдим итү.

4) Җөмләләрдәге төгәлсезлекләрне табарга өйрәтү.

5) Башкача ничек әйтеп була?

4. Физкультпауза: «Капма-каршысын әйт».

Ак — кара, тапты — югалтты, көн — төн, җиңел — авыр, югары — түбән.

IV. Укытучының йомгаклау сүзе.

— Күрәсезме, укучылар, безнең телебез нинди бай! Ул көн саен баийй бара. Телебезгә яңа сүзләр керә. Мәсәлән, без кечкенә чакта *марс, сникерс, компьютер* дигән сүзләр юк иде. Алар безгә башка телләрдән кереләр. Ә кайберләре телебездән төшеп тә калалар. Мәсәлән: *октябрят, коммунист, совет* сүзләре сирәк кулланыла башлады.

Телебездәге байлыктан файдалана белү өчен күп кагыйдәләрне өйрәнергә кирәк. Без бу эшне башка дәресләрдә дәвам итәрбез.

V. Өй эше.

1. Табышмаклар язып килергә:

1 нче рәткә — табигать күренешләре турында;

2 нче рәткә — яшелчә, җиләк-җимеш турында;

3 нче рәткә — кеше турында.

2. Телебезнең байлыгы, матурлыгы турында хикәя төзеп сөйләргә өйрәнергә.

21 нче дәрес

Тема: Табышмак уйлап чыгарабыз.

Максат: 1. Табышмаклар төзү ысуллары белән таныштыру. 2. Логик фикерләү сәләтләрен үстерү. 3. Халык авыз иҗаты әсәрләренә хөрмәт тәрбияләү.

Материал: «Балалар фольклоры». Казан, 1998; табышмаклар.

Дәрес барышы

I. Дәреснең темасы һәм максаты белән таныштыру.

1. Дәреслектә бирелгән табышмакның җавабын табу.

2. *Табышмакның җавабын нинди билгеләре буенча табып була?* соравына җавап бирү.

1 нче билге: үрмәкүч челтәр бәйләүче итеп сурәтләнгән.

2 нче билге: үрмәләп эшләве сурәтләнә.

Шул билгеләренә карап, үрмәкүч икәнен белеп була.

II. Табышмак уйлап чыгару үзенчәлекләре белән танышу.

Әйберне нәрсәгә дә булса ошатырга һәм ул әйбернең билгеләрен санап чыгарга кирәк (дәрес өчен кирәкле пластинканы укытучы алып килә).

1. Пластинка турында табышмак уйлап карыйк әле. Ул нәрсәгә охшар? (Тәгәрмәчкә.) Хәзер бу тәгәрмәчне тасвирлыйк инде. Бу нинди тәгәрмәч? (Гади түгел.) Анда нәрсәләр бар? (Сырлар.) Ул нишли? (Әйләнә.) Ничек итеп әйләнә? (Җырлый-җырлый әйләнә.) Аның җырлары кайда? (Сырларында.) Җавапларны тактага язып барыйк.

Шушы язганнарны шигъри дүртьюллык итеп әйтик (табышмакны дәреслектән уку).

2. Берничә табышмакның ничек төзелүен тикшереп чыгу.

Бирелгән табышмакларны уку, нәрсә белән чагыштырып төзелүләре турында сөйләшү. Билгеләре генә саналган табышмакларга мисаллар китерү.

1) Өстәлемдә ак үгез,
Маңгаенда — бер мөгез.
(Чәйнек)

2) Гөрли-гөрли җырлый ул,
Кызыл читек кия ул.
Күлмәкләре күгелҗем,
Татулыкны сөя ул.
(Күгәрчен)

Бер әйбергә дә охшатылмый, билгеләре генә санала, дип нәтиҗә ясала.

III. Ныгыту күнегүләре. 1. Зонтик турында чагыштырып табышмак уйлап чыгару (мөстәкыйль эшкә).

2. Табышмаклар әйтешү (өй эшен тикшерү).

IV. Йомгаклау.

— Табышмаклар безгә ни өчен кирәк? (Җавап.) Табышмакны кемнәр уйлап таба? (Җавап.) Табышмаклар безне нәрсәгә өйрәтә?

V. Өй эше.

1. Хайваннар яки кошлар турында табышмаклар өйрәнеп килергә.

2. Әтәч, песи яки эт турында табышмак иҗат итәргә.

22 нче дәрес

Тема: Үзебез әкият язабыз.

Максат: 1. Балаларның фантазиясен, хыяллана белүен үстерү. 2. Аларның сүзлек запасын баету. 3. Халык авыз иҗаты әсәрләренә хөрмәт, алар белән кызыксыну тәрбияләү.

Материал: «Татар халык әкиятләре». Казан, 1989; алдагы елларда балалар язган әкиятләр.

Дәрес барышы

I. Әкиятләр, аларның авторлары турында кереш әңгәмә.

1. Халык әкиятләре.

2. Язучылар язган әкиятләр (Г. Тукай, А. Алиш, Х.-К. Андерсен, А. С. Пушкин).

3. Балалар язган әкиятләр.

II. Яңа материал.

1. «Татар халык әкиятләре» китабыннан бер әкият уку. («Карчык белән Аю», 65 нче бит)

2. Икенче вариант: әкиятне укымыйча, сөйләтергә генә дә була.

Башка вариант: укытучы теләге буенча, «Сабантуй» газетасында басылган укучылар әкиятен дә файдаланырга була.

3. Аннан соң алдагы елларда укучылар язган әкиятләр укыла.

4. Бер таныш әкиятне уйнау. Мәсәлән: «Кызыл калфак һәм Бүре» әкиятен уйнау.

5. Укытучының тәкъдиме белән физкультминут шушы әкияткә бәйләп үткәрелә. Кызыл калфак, Бүре, Әби, урманчылар, Әнидән кала башка балалар барысы да агачлар булалар. Алар җилдә тирбәләләр, Кызыл калфак белән Бүре очрашканда, каты итеп селкенәләр.

6. Укытучының әкият сөйләве.

7. Әкияткә яңа геройлар өстәү.

— Әйдәгез, Айсылуга Шаянны коткарырга ярдәм итик. Моның өчен әкияткә яңа геройлар кертик. Мәсәлән: Урман хуҗасы һәм тылсымлы велосипед.

8. Бергәләп әкиятне тулыландыру, яңа әкият язу.

Айсылу йокысыннан уянуга: «Шаян, Шаян!» — дип эндәшеп караган. Әмма Бәбкә бер җирдә дә күренмәгән. «Аны Төлке ашый күрмәсен!» — дип, бик кайгырып, Айсылу Шаянны эзләп киткән. Бара икән, бара икән. Караса, бер Бака баласы елап утыра икән. Айсылу аңа: «Нигә елыйсың?» —

дигән. Бака баласының аягы сынган икән. Кыз аны әйбәтләп бәйләп куйган да тагын да кызурак киткән. Үзе һаман: «Шаян, Шаян!» — дип, бәбкәгә эндәшкән. Нindидер кош тавышын ишетеп, кыз туктап калган. Караса, нәни генә кошчык оясыннан егылып төшкән. Айсылу аны оясына куйган. Кыз тагын да тизрәк барырга тырышкан. Шулай барганда, авыр-авыр сулаган тавыш ишеткән. Караса, кемдер нәни агачның башына басып киткән. Ул ничек тә булса күтәрелергә тырыша икән. Айсылу аңа ярдәм иткән. Алга таба барыйм дисә, каршысында Урман хуҗасын күргән.

— Син бик игелекле бала икәнсең, мин кайчаннан бирле синең арттан киләм. Әйт, башыңа нинди кайгы килде, мин сиңа ярдәм итәрмен,— дигән.

Айсылу аңа Шаян турында сөйләп биргән.

Урман хуҗасы Айсылуга тылсымлы велосипед бүләк иткән. Ул бик тиз дә бара икән, суларда да, сазлыкларда да батмый икән. Айсылу, рәхмәт әйтеп, велосипедка утырып киткән, Төлкене куып җиткән, Бәбкәне тартып алган һәм өенә алып кайткән.

III. Ныгыту күнегүләре.

а) Укучыларның белгән әкиятләрен сөйләтү.

б) Дәреслектәге рәсемне карау. Әкияттәге буталган геройларны ачыклау («Кызыл калфак» һәм «Сертотмас үрдәк» әкиятләре).

в) Белемнәрне тестлар ярдәмендә ачыклау.

Әкиятләре матбугатта басылган язучылар:

1) Фәнис Яруллин
2) Габдулла Тукай
3) Роберт Миңнуллин

Бу юллар кайсы әкияттән?

Арпадан да үттем,
Көрпәдән дә үттем,
Инде ачып караем.

1) «Аю белән өч кыз»
2) «Карчык белән Аю»
3) «Аю белән Хатын»

«Су анасы» әкиятендә катнашучы геройлар:

1) Автор, Су анасы, Малай
2) Су анасы, Шүрәле, Малай
3) Су анасы, Малай, Әнисе

«Сертотмас үрдәк» әкиятен кем язган?

1) Габдулла Тукай

2) Абдулла Алиш
3) Муса Җәлил

Әкиятләрне кем иҗат итә ала?
1) Халык
2) Язучылар
3) Балалар

IV. Өй эше.

1. Үзегез уйлап әкият языгыз.
2. Дәрестә өйрәнгән берәр әкияткә иллюстрация ясарга.

23 нче дәрес

Тема: Күңелле хикәяләр.

Максат: 1. Балаларны күңелле хикәяләр белән таныштыру. 2. Укучыларны урынлы көлә белергә өйрәтү, аларда юморны аңлый белү тәрбияләү. 3. Сәнгатьле уку һәм йөгерек сөйли белү күнекмәләрен үстерү өстендә эшләүне дәвам итү.

Материал: В. Нуриевның «Инша», «Чук һәм Гек» һәм дә... Ирек»; Р. Гыйззәтуллинның «Имәндә икән чикләвек!» хикәяләре; «Чаян» журналы.

Дәрес барышы

I. Дәреснең темасы, максаты белән таныштыру.

— Күңелле хикәяләр кешеләрдә елмаю уяталар. Ә көлү — җитди эш. Көлә белеп көләргә кирәк. Әгәр син егылган иптәшеңнән, пычракка кереп уйнаган кечкенә баладан көлсәң, бу бер дә дөрес түгел. Һәр кеше, чын көлкеле вакыйганы күреп, рәхәтләнеп көлә белсә иде. Бүген без шундый хикәяләр белән танышырбыз.

II. Яңа материалны аңлату.

1. В. Нуриевның «Инша» хикәясен уку.
2. Сораулар буенча эчтәлекне ачыклау:

— Сезгә бу хикәя кызык тоелдымы? (Җавап.) Кайсы өлешләре бигрәк тә көлке тоелды?

3. Хикәянең эчтәлеген сөйләтү. Сайлап уку күнегүләре.
4. Физкульт-музыкаль тәнәфес.
5. Рәсемнәр буенча күңелле хикәя төзү.

Укытучы сюжетлы рәсемнәрне бутап куя. Укучылар аның башын, уртасын, ахырын дөреслэп урнаштыралар. Рәсемнәр буенча күңелле хикәяләр төзиләр.

Нәтиҗә: Көлкеле хикәяләрне рәсемнәрдә дә чагылдырып була.

6. Карикатуралар турында сөйләшү.

— Сезнең карикатураларны кайларда күргәнегез бар? «Чаян» журналыннан берничә карикатура карау.

7. Көлкеле хикәяләрне үзебез дә яза алабыз.

Һәр рәткә дәфтәр бите җибәрелә. Укучылар укытучы биргән сорауга җавап язалар. Җавапларны бөкләп куялар. Дәфтәр бите чираттан бирелә.

— Бу хәлләр кайчан булды?

— Анда кемнәр катнашты?

— Аның төп герое кем?

— Ул нинди?

— Ул анда нишләде? һ. б. шундый сораулар бирелә.

Соңыннан һәр битне ачып укыйлар һәм иң кызык хикәяне сайлыйлар.

8. Р. Гыйззәтуллинның «Көтелмәгән сорау» китабыннан «Имәндә икән чикләвек!» хикәясен уку.

III. Өйгә эш.

1. Хикәяне укырга һәм кызык итеп сөйләргә өйрәнергә.

2. Шатлыклы, кайгылы, сөенече бик зур булган кешене мимика һәм хәрәкәтләр ярдәмендә күрсәтергә.

24 нче дәрес

Тема: Мәзәкләр.

Максат: 1. Укучыларны мәзәкләр белән таныштыру. 2. Балаларны үткен сүзлелеккә, төрле ситуацияләрдә югалып калмаска өйрәтү. 3. Бер-берләре белән аралаша белү күнекмәләрен үстерү өстендә эшләү.

Материал: «Хуҗа Насретдин мәзәкләре» китабы.

Җиһазлау: «Сабантуй» газеталары, «Чаян», «Салават күпере» журналлары.

Дәрес барышы

I. Өй эшен тикшерү.

1. Р. Гыйззәтуллинның «Имәндә икән чикләвек!» хикәясен кызык итеп сөйләү күнегүләре. Иң кызык итеп сөйләүчене сайлау.

2. Мимика һәм хәрәкәтләр белән кешеләрнең кәефләрен чагылдыру.

II. Актуальләштерү, үткәннәрне кабатлау.

— Кызык хикәяләрне генә шулай кызык итеп сөйләп буламы? Тагын шундый күңелле әйберләр ишеткәнегез юкмы?

— Мәзәкләр, анекдотлар, йөремсәк мәзәкләр.

— Сезгә мәзәкләр кайларда очраганы бар? (Газета-журналларда, китапларда.)

— Кемнәр турында мәзәкләр укыганыгыз бар? һ. б.

III. Яңа материал.

1. Укучылар алып килгән «Сабантуй» газеталарыннан мәзәкләр уку, сөйләү. Кайсы өлеше ни өчен ошаганын билгеләү. Һәркайсы үз фикерен әйтә.

2. Милли мәзәкләр турында төшенчә бирү.

3. Китаптан берничә мәзәк уку. Хуҗа Насретдинның зирәклеген, югалып калмавын, үткен телле булуын билгеләү.

4. Мәзәкләрне үзеңчә дәвам иттерү.

— Ни өчен юлбарыс чи ит ашый?

(Вариант: чөнки пешерә алмый.)

— Менә, улым, син елаудан да туктадың.

— Туктамыйм әле мин...

(Вариант: әзрәк ял гына итәм.)

— Төньякта яшәүче алты җәнлекне санап чык.

(Вариант: дүрт ак аю һәм ике тюлень.)

5. Ситуацияләрне уйнап күрсәтү.

1) — Фамилиягез? — дип сорый укытучы.

....

2) Бер малай уку әсбаплары кибетенә керә.

— Апа, сездә беренче сыйныфлар өчен клей бармы?

— Юк, энем.

— Ә түгәрәкле дәфтәрләр?

— Түгәрәкле дәфтәрләр булмый, сызыклы я шакмаклы гына була.

Шулчак артта басып торган бер агай:

— Сатучының башын әйләндермә! Мәгънәсез әйберләр сорап, аның күпме вакытын аласың! — ди.— Сеңлем, миңа Украина глобусы бирегезче.

IV. Йомгаклау. Үзең күргән, ишеткән хәлләр буенча да мәзәкләр сөйләп була. Укучыларның үзләренә дә мәзәк язып карарга тәкъдим итәргә мөмкин.

V. Өй эше.

Китапханәдән «Хуҗа Насретдин мәзәкләре»н алып укырга, үзегезгә иң ошаган мәзәкләрне кызык итеп сөйләргә өйрәнергә.

25 нче дәрес

Тема: Балалар газеталары белән таныштыру.

Максат: 1. Укучыларны балалар газетасындагы материалларда дөрес «ориентлашырга» өйрәтү. 2. Газета-журналларны көндәлек укып барырга күнектерү. 3. Балаларда матбугатка язарга теләк уяту.

Материал: «Сабантуй» газеталары; В. Нуриевның «Фельетон яза Фәсхетдин» хикәясе.

Дәрес барышы

I. Дәреснең максаты белән таныштыру.

— Сез Галимҗан Латыйпның «Зәйнәп апа» шигырен беләсез. Зәйнәп апа кем булып эшли? Ул нәрсә тарата? (Җаваптан соң.) Сез нинди газета-журналлар аласыз? Шуларның кайсылары балалар өчен чыгарылган? (Җаваптан соң.) Бүген без балалар газеталары турында сөйләшербез. Газетадан үзебезгә кирәкле мәгълүматны табарга өйрәнербез.

II. Яңа материал.

1. Балалар газетасы «Сабантуй»ның бизәлешен бергәләп күзәтү.

— Газетаның исемен укыгач, нинди мәгълүматлар алдыгыз? (Номер, көн, ай исеме, ничә тапкыр чыга һ. б.)

— Балалар газетасы башка газеталардан нәрсә белән аерыла? (Балалар газетасы матур итеп бизәлгән, рәсемнәр һәм фотографияләр күп.)

2. Газета материаллары белән танышу.

Балалар газетаны карыйлар, үзләре кызыксынган мәкаләләрне, аларның исемнәрен укыйлар. Иң беренче биттә мөһим хәбәрләр урнашканлыгы әйтелә. Шундый хәбәрне табып, укып карыйлар.

3. Газетада «ориентлашырга» өйрәтү, «юл билгеләре» белән таныштыру.

— Ни өчен кайбер мәкаләләрнең исемнәре зур хәрефләр белән басылган?

4. Газетага мәкалә язучылар белән танышу.

«Сабантуй» газетасының авторы — балалар. Иң соңгы биттә, аста газетаның адресы, телефоннары бирелгән.

5. Балаларга газетага мәкалә язып карарга тәкъдим итү.

6. Физкульттәнәфес.

III. Йомгаклау.

В. Нуриевның «Бүре кадәр бүрек» дигән китабы белән таныштыру.

IV. Өй эше.

1. Сыйныфыгызда үткәрелгән кызыклы чараларның берсе турында мәкалә языгыз.

2. В. Нуриевның «Фельетон яза Фәсхетдин» дигән хикәясен укырга, сөйләргә өйрәнергә.

26 нчы дәрес

Тема: Газета-журналлардагы фоторәсемнәр.

Максат: 1. Укучыларны газетадагы фотографияләр һәм аның астындагы язулар белән таныштыру. 2. Рәсем асларына текст яза белергә күнектерү. 3. Журналист хезмәте белән кызыксыну уяту.

Материал: «Сабантуй», «Көмеш кыңгырау» газеталары, «Ялкын» журналы; В. Нуриев. «Бүре кадәр бүрек». Казан, 1991.

Җиһазлау: Сыйныф, гаилә белән төшкән карточкалар.

Дәрес барышы

I. Кереш әңгәмә.

— Ни өчен газета-журналларда фотографияләр бирелә? (Мәкаләдә нәрсә турында сөйләнгәнен күрсәтеп тору өчен.)

— Газетадан берәр кызыклы фотографияне табыгыз. Аның астында бирелгән текстны укыгыз. Анда нәрсә турында сөйләнә? Ни өчен бу рәсемне газетага урнаштырганнар дип уйлыйсыз?

II. Яңа материал.

1. Фотографияләргә карата бирелгән язуларга анализ ясау.

— Фоторәсемнәр бирелгән текстны бизәп кенә калмыйлар, үзләре дә информация бирәләр. Фоторәсем астына язылганнардан *нәрсә? кайда? кайчан?* сорауларына җавап табарга мөмкин.

2. Укучылар үзләре бер фотографияне карыйлар, аңа карата бирелгән текстны укыйлар. Текстның фотографиядә күрсәтелгән вакыйганы ачу-ачмавын тикшерәләр.

3. В. Нуриевның «Җәйге кар» дигән хикәясен уку.

— Бу малайның фоторәсемен күз алдына китерегез. Ул аңа нинди исем куярга булган?

4. Дәреслектә бирелгән рәсем буенча фикер алышу, нәтиҗә ясау.

III. Йомгаклау.

Укучылар алып килгән карточкаларны карау, сораулар буенча сөйләм төзү.

— Фотографиядә кем һәм нәрсә сурәтләнгән?

Рәсемдә сурәтләнгән вакыйгага карата иң кызыклы җөмлә төзү күнегүләре оештырыла.

IV. Өй эше.

Үзегезнең гаилә яки сыйныфыгыз белән төшкән фотокарточкагызга рәсем асты языгыз.

27 нче дәрес

Тема: Исемең матур, кемнәр куйган?

Максат: 1. Татар телендә кеше исемнәренең нindидер мәгънәгә ия булуларын аңлату. 2. Төрле телләрдән кергән кеше исемнәре белән таныштыру. 3. Балага исем сайлауга бик җаваплы карарга кирәклегенә төшендерү.

Материал: Г. Саттаров. «Татар исемнәре ни сөйли?». Казан, 1998.

Дәрес барышы

I. Дәреснең темасы һәм максаты белән танышу.

— Дөньядагы һәр нәрсәнең исеме бар. Кешеләр, җанварлар, елга-күлләр, тыкрык-урамнар да нindидер исемгә ия. Ә ул исемнәр уйламыйча гына кушылмаган.

Без бүген кеше исемнәренең мәгънәләре белән танышырбыз.

II. Яңа материал.

1. Г. Мөхәммәтшинның «Без әле җирдә яшибез» повестеннан өзек уку.

Сорауларга җавап:

— «Инсафлы» дигән сүз нәрсәне аңлата? (Җаваптан соң.) Сез нинди малайлар исемнәре беләсез? (Җаваптан соң.) Үз исемегезнең мәгънәсен беләсезме?

2. Физкульт-музыкаль тәнәфес.

3. Исемнәрнең төрле мәгънәләр белдерүе белән танышу.

— Яңа туган сабыйга кушу өчен исем эзләгәндә, ул исемнең җыйнак, җиңел әйтелә торган, яхшы мәгънәле булырга тиешлеген истә тоталар.

4. Исемнәр тарихына күз салыйк.

«Җан» төшенчәсен белдерә торган исемнәр турында дәреслек буенча укып өйрәнү.

— Хәзер кушыла торган исемнәрнең дә мәгънәләре бар. Аларның күбесе безгә гарәп, фарсы, борынгы төрки телләрдән кергәннәр. Гарәп телендә *Фазыл* «талант иясе» дигәнне аңлата. *Рөстәм* сүзе фарсы телендә «бик зур, алып гәүдәле, әзмәвер» дигәнне аңлата. *Ясирә* исеме «кечкенә, бәләкәй, кыска, кече» мәгънәсенә ия.

5. Кушма исемнәр турында сөйләшү.

— Хәзер тамыр сүзгә тамыр сүз кушып ясалган исемнәр уйлап карыйк. Болар нинди исемнәр?

— *Илшат, Илүсә, Гөлнур, Айгөл* һ. б. Андый исемнәрне кем күбрәк таба ала?

6. Табигатьтәге күркәм әйберләр, күренешләрне белдерүче сүзләрнең исем итеп алынуын аңлату.

— Ялгызлык һәм уртаклык исем була торган исемнәр бар. Моңа нинди мисаллар китерә аласыз?

— *Бүләк, Кояш, Тамчы, Йолдыз, Ландыш, Ләйсән* һ. б.

7. Кыскартылган кушма исемнәрне әйтеп китү.

— Революцион вакыйга, атаклы кешеләрнең исеменнән кыскартып ясалган исемнәр була: *Вил* (Владимир Ильич Ленин), *Ленар-Ленара* (Ленинская армия), *Дамир-Дамира, Рево, Люция*.

8. Нәтиҗә ясау.

— Исем кешегә бер генә мәртәбә бирелә һәм аның гомерлек юлдашына әверелә. Һәр кеше үз исеменә шулкадәр күнегә ки, хәтта ул аның туган теленең иң кадерле сүзе булып тоела.

9. Кешенең исеме җисеменә туры килеп торса иде.

И. Туктарның «Өлгер» хикәясен искә төшерү. *Өлгер нинди малай?* соравына җавап бирү.

Бу дәрестә балага исем кушу йоласы белән дә таныштырырга була.

10. Физкульттәнәфес.

III. Йомгаклау.

1. Шигырьләрдән өзекләр уку.

1) Әйдә уйнарга, Аяз,
Бүген көн матур, аяз.

Исеме аның Иркә,
Үзе дә ул бик иркә.

Ш. Галиев

— Бу өзектәге кеше исемнәре ничек ясалган?

2) Илгиз нинди үскән бала:
Үзе торып баса ала!
Батыраеп атлап китә,
Аяклары тып-тып итә.

Ә. Кари

3) Камил әле бик кечкенә,
Үрмәләп йөри иде,
Ә бакчага бүген менә
Ул тәпи-тәпи килде.

Ә. Бикчәнтәева

2. Укучыларның белемнәрен тикшерү өчен тест сорауларына җавап алу.

Исемнәрнең кайсы пары дөрес түгел?

1) Энҗе, Бриллиант
2) Миләүшә, Фиалка
3) Гөлнур, Гөлсем

Кайсы исемнәр кушма түгел?

1) Илнур, Илшат, Гөлбану
2) Йолдыз, Кояш, Ләйсән
3) Айгөл, Гөлшат, Гөлназ

Кайсы исемнәрне кызларга да, малайларга да кушалар?

1) Рәйхан
2) Илнар
3) Фирдәвес

Рус һәм Европа телләреннән кергән исемнәрне билгеләгез.

1) Әлфия, Самат
2) Рафаэль, Регина
3) Гөлназ, Азат

Чәчәк һәм кеше исемнәре булырга мөмкин сүзләрне билгеләгез.

1) Миләүшә
2) Энҗе
3) Әминә

IV. Өй эше.

1. Үз исемегезнең мәгънәсен белеп килегез.
2. Гаиләдәге кешеләрнең исемнәре нинди мәгънә аңлатуы турында өйрәнеп, язып килергә.

28 нче дәрес

Тема: Үзем турында сөйлим.

Максат: 1. Укучыларда үзләре турында сөйләү теләге уяту һәм сөйләм күнекмәләре булдыру. 2. Сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү.

Материал: Ш. Галиевнең «Мин», «Иләвәш сере»; Р. Миңнуллинның «Бик әйбәт минем эшләр» шигырьләре; Г. Мөхәммәтшинның «Без әле җирдә яшибез» повестеннан өзек.

Дәрес барышы

I. Үткәннәрне кабатлау, өй эшләрен тикшерү.

II. Дәреснең темасы, максаты белән таныштыру.

1. Ш. Галиевнең «Мин» һәм «Иләвәш сере» шигырьләрен уку. Сорауларга җавап бирү.

— Шәвәли нинди малай? (Җаваптан соң.) Аның кайсы сыйфатлары сезгә ошый, ниндиләре ошамый? (Җаваптан соң.) Иләвәш кем соң ул?

2. Р. Миңнуллинның «Бик әйбәт минем эшләр» шигырен укып анализлау. Сорауларга җавап бирү.

3. Үзең турында җитди итеп тә, шаяртып та сөйләргә була. Үзең турында үзең сөйләүне автобиография диләр. Без аның турында алдагы дәресләрдә сөйләшербез.

Ә бүген, шигырьләрдә бирелгәнчә, үзебез белән җиңелчә шаяртып таныштырыйк әле. Аңарчы Г. Мөхәммәтшинның «Без әле җирдә яшибез» повестеннан өзек тыңлагыз.

«Нишләргә?» Шушындый уйлар белән Әхмәдигә якынлаштым.

Ул тамагын кырды да суга төкерде. Йодрыгын йомарлап:

— Әй шәһәр чыпчыгы! Кәнфит тамак! Аркам кычыта, дип әйткән идең. Кил, кашыйм! — дип кычкырды.

Минем аяклар күпер тактасына беректеләр дә каттылар. Гәрәй безнең арага керде, аркасы белән мине каплады. Әхмәди Гәрәйне якасыннан тотып читкә селтәп атты. Минем биткә йодрыгы белән китереп төртте. Ул икенче тапкыр төртергә өлгермәде. Нишләгәнемне үзем дә белмәдем. Сорасалар, хәзер дә әйтә алмыйм. Теге йодрыгын күтәрә башлауга, кизәнеп, сумкам белән башына бирдем. Әхмәди күпер рәшәткәсенә килеп бәрелде. Күзләрен челт-челт йомып, минем шикелле, ни булганын аңламыйча, аңгыраеп торды. Аннан кинәт сикереп минем өскә атылды. Мин, аның җиле бәрелгәч тә, артка

егылып киттем. Без, уфылдый-уфылдый, такталар өстендә тәгәрәргә тотындык. Әхмәди күкрәге белән мине күпер тактасына китереп кысты. Менә бетәм, соңгы сулышымны алам икән дип ятканда, кинәт тын алуы рәхәт булып калды. Кемдер мине торгызды, өстемне какты. Рәтләнгәч, Әхмәдигә борылдым. Аның якасыннан көчле беләкле Минһаҗ тотып тора иде...»

— Инсаф үзе белән булган нинди вакыйга турында сөйли?

4. Үзегез турында бер вакыйганы алып, хикәя төзегез.

5. Укучылар, мөстәкыйль рәвештә, үзләре турында шаян хикәя төзиләр.

III. Өй эше.

1. Хикәяне язып бетерергә.

2. Үзеңнең яраткан шөгылеңтурында күңелле итеп сөйләргә өйрәнергә.

29 нчы дәрес

Тема: Синең тормышыңның бер көне.

Максат: 1. Укучыларны таныш булмаган кешеләргә үзләре турында сөйләргә өйрәтү. 2. Кеше сөйләгәнне игътибар белән тыңлый белү күнекмәләрен үстерү өстендә эшләү. 3. Тыйнаклыкның кешеләрне иң күркәм итүче сыйфат икәнлегенә төшендерү.

Материал: Р. Миңнуллинның «Көтү әйбәт көтелгән» шигыре, «Ялкын» журналыннан хикәя.

Дәрес барышы

I. Дәреснең максаты белән таныштыру.

«Минем тормышымның бер көне» китабы турында укытучы сөйләве.

II. Яңа материалны аңлату.

1. Ун яшьлек Катекита исемле малайның хикәясен уку.

2. Сорауларга җавап:

— Катекита кайда яши? (Җаваптан соң.) Аның тормышы турында сез ниләр белдегез? (Җаваптан соң.) Энҗе җыю турында язылган урынны гына сайлап укыгыз. Бу гаиләдә ничә кеше яши?

3. Физкульттәнәфес.

4. Катекитаның хикәясен анализлау.

5. Р. Миңнуллинның «Көтү әйбәт көтелгән» шигырен уку, сорауларга җавап бирү.

III. Мөстәкыйль эш. «Минем тормышымның бер көне» дигән хикәя төзү һәм кульязма китап әзерләү.

IV. Йомгаклау. Балалар язган хикәяне тыңлау.

3 нче сыйныф укучысы Мөхетдинова Диләрә язган хаттан өзек:

«...Синең Татарстан турында ишеткәнең бармы? Мин Татарстан Республикасының Балтач авылында яшим. Бездә кыш та, яз да, җәй дә, көз дә була. Без кыш көне чана, чаңгы, тимераякта шуабыз, кар белән уйныйбыз. Мин кар-кар дип әйтәм, син әле карның нәрсә икәнен дә белмисеңдер. Мин сиңа кар бөртегенең рәсемен ясап күрсәтәм.

Җәй көне, җиләкләр пешкәч, урманга барабыз. Безнең туган ягыбыз яз көне дә, көз көне дә бик матур була.

Без гаиләдә биш кеше яшибез: әти, әни, абый, сеңлем һәм мин. Әти белән әни эшлиләр. Без өчебез дә мәктәптә укыйбыз.

Кадерле дустым! Син дә үз илең турында хат язып җибәр. Сәлам белән: Диләрә».

V. Өй эше.

1. Китабыгыз матур булсын өчен, язмагызны рәсемнәр белән бизәгез.

2. Әти-әниегез турында сөйләргә өйрәнеп килегез.

<u>30 нчы дәрес</u>

Тема: Синең тәрҗемәи хәлең — биографияң.

Максат: 1. Балаларны үз тормышларында булган төп вакыйгаларны танып белергә өйрәтү. 2. Анкета сорауларына төгәл, кыска итеп җавап бирергә күнектерү. 3. Биография (автобиография) сөйләү һәм язуның үзенчәлекләре белән таныштыру.

Материал: Г. Тукай «Исемдә калганнар».

Дәрес барышы

I. Дәреснең максаты белән таныштыру.

— Сезнең бер-берегез белән әти-әниләрегез, торган өйләрегез, туган авылыгыз турында сөйләшкәнегез бармы? Әйдәгез әле, өйдә язып килгән хикәяләргә күз салыйк. Без ниләр белә алырбыз икән?

II. Яңа материал.

1. Биография, автобиография турында укытучы аңлатуы.

2. Анкета сорауларына җавап бирү.

3. Автобиография язарга өйрәтү.

— Анкета сорауларын кулланып, автобиография язабыз. Язганда төгәл булырга кирәк. Кеше исемнәре һәм даталар күп булуга игътибар бирегез. Автобиография болай башлана: «Мин, Гарипова Алсу Мансуровна, 1981 елда .... районы, ... авылында туганмын».

4. Дәреслектә бирелгән автобиография үрнәген уку.

5. Биографик һәм автобиографик әсәрдән өзекләрне чагыштыру.

III. Йомгаклау. Г. Тукайның «Исемдә калганнар» дигән автобиографик әсәреннән өзекләр уку.

IV. Өй эше.

1. Г. Тукайның «Исемдә калганнар» әсәреннән үзегезгә иң охшаган урынны сөйләргә әзерләнегез.

2. Гаилә, әти-әни, аларга хөрмәт турында бишәр мәкаль өйрәнеп килегез.

31 нче дәрес

Тема: Гаиләдә үзара мөнәсәбәтләр.

Максат: 1. Укучыларны гаиләдә әти-әнигә, башка туганнарга нинди мөнәсәбәт булырга тиешлеге белән таныштыру. 2. Гаиләдәге татулыкның нигезе турында әңгәмә. 3. Халык авыз иҗаты әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләү, аларны урынлы файдаланырга өйрәтү.

Материал: «Балалар календаре», татар календарьлары, «Сабантуй» газетасы, «Татар халык иҗаты» сериясеннән «Мәкальләр һәм әйтемнәр»; Р. Миңнуллинның «Өйрәнә»; Җ. Дәрзаманның «Солдат булдым» шигырьләре.

Җиһазлау: Гаиләләргә багышлап чыгарылган стена газетасы, «Минем өем» дигән рәсемнәр күргәзмәсе, әдәби китаплар, шигырь язылган таблица.

Дәрес барышы

I. Өй эшен тикшерү.

1. Укылган әсәрнең эчтәлеген сөйләү. Г. Тукай турында белгәннәрне системалаштыру.

2. Укылган китаплар буенча әңгәмә.

— Ләйсән, син бүген нинди китап укыдың? (Җаваптан соң.) Син аның тагын нинди әсәрләрен беләсең? (Җаваптан соң.) Рәмис, синең китабың кызыклымы? Безгә аны тәкъдим ит әле. (Җаваптан соң.) Тагын кем үзе укый торган китапны безгә тәкъдим итәргә тели?

3. Укучыларга яңа китап тәкъдим итү.

— Минем үземнең дә сезгә бер китап тәкъдим итәсем килә. Бу — татар халкының мәкальләр һәм әйтемнәр китабы. Бу китапка 18405 мәкаль һәм әйтем тупланган. «Риторика дәресләре безне әдәпле, дөрес, төгәл итеп сөйләшергә, аралашырга өйрәтә»,— дигән идек. Мәкальләрдән һәм әйтемнәрдән дә тапкыррак итеп әйтергә һич мөмкин түгел. Мин сезгә өй эшен шуның буенча биргән идем.

4. Гаилә әгъзалары турында өйрәнеп килгән мәкальләрен, әйтемнәрен сорау.

5. Нәтиҗә ясау.

— Әйдәгез, мәкальләр, әйтемнәр буенча нәтиҗә ясап карыйк.

1) Гаиләдә иң өлкән кешеләр — әби белән бабай. Алар — иң зур хөрмәткә лаек кешеләр.

2) Әти белән әни — иң якын кешеләр. Аларның киңәшләрен һәрвакыт тыңларга кирәк.

3) Гаиләдәге абый-апалар, эне-сеңелләр белән дус яшәргә кирәк.

6. Фикерләрне дәлилләү.

— Өлкән кешеләр буларак, хөрмәтләүне әби-бабайлардан башларга кирәк, дидек. Бу турыда нинди әсәрләр укыганыгыз бар? Әсәрләрнең кыскача эчтәлеген файдаланып, дәлилләп күрсәтегез.

1) Л. Н. Толстойның «Бабай һәм онык» хикәясен искә төшерү, эчтәлеген сөйләтү.

Дәреслектәге билгеләмәне уку.

2) Әти-әниләрне ярату, аларны иң якын кешеләр итеп хөрмәтләү турында безнең бик күп сөйләшкән бар. Аны бу хактагы җырларның исемнәре генә дә әйтеп тора. Мәсәлән: «Әнкәмнең догалары», «Су буеннан әнкәй кайтып килә», «Әниемнең җылы кочагы», «Әниемә», «Җырлыйм әнием турында».

— Әйдәгез, берәрсен искә төшерик. Әниләргә хөрмәт йөзеннән басып җырлыйк. (Җыр башкарыла.)

— Ә менә әтиләр турында, нишләптер, җырлар аз язылган.

Ни өчен икән? Сез ничек уйлыйсыз? (Җаваптан соң.) Әтиләр турында нинди шигырьләр беләсез?

7. Җ. Дәрзаманның «Солдат булдым» шигыре өстендә эш.

— Ата кеше гомер буе гаиләнең терәге булып саналган. Элек балалар әти янында кычкырып та сөйләшмәгәннәр, аның ризалыгыннан башка бер эш тә эшләмәгәннәр. Әти кайдан да булса кайтып керүгә, аның аяк киемен салдырганнар, кулын юарга җылы су белән комган, сөлге әзерләп торганнар. Әтинең кулын юдыру бик саваплы, мәртәбәле эш саналган.

8. Менә хәзер комганнар юк. Әтиегез эштән кайтты дип уйлыйк. Сез аны ничек каршы алыр идегез? (Ситуация уйнала.)

— Аяк киемнәрен салгач, өйдә кия торган башмакларын китереп бирә алабыз. Җылы су краннан килмәгәндә, су әзерләп куярга кирәк, сөлге бирә алабыз.

9. Әти-әниләр безне гел яхшылыкка өйрәтә. Алар әле без зур булгач та, безнең өчен борчылалар. Еракларга китсәң, әти-әнине онытмыйча, күчтәнәчләр белән кайтып йөрергә, андый мөмкинчелекләр булмаганда, хатлар, күчтәнәчләр, бүләкләр җибәреп торырга кирәк.

III. Ныгыту күнегүләре.

1. А. М. Горькийның улы Максимга язган хатыннан өзекне укып анализлау.

«...Бүләгең өчен рәхмәт, улым. Син бик әйбәт киштә эшләгәнсең. Кошлар турындагы китаплар ошыймы?.. Укырга өйрән, эшләргә өйрән. Эш белмәгән кеше начар кеше ул. Ә син яхшы кеше булырга тиешсең... Син үзең киттең, ә утырткан чәчәкләрең биредә калды, үсәләр алар. Мин шул чәчәкләргә карыйм да, улым Каприда бик яхшы нәрсәләр — чәчәкләр калдырып китте, дип шатланам... Син шуны бел: кешедән алуга караганда, кешегә бирү — күңеллерәк».

2. Иҗади күнегүләр:

— Менә сез үзегез дә — киләчәктә булачак әти-әниләр. Үзегезнең улыгызга, кызыгызга нәрсәләр язар идегез? (Җаваптан соң.) Язучыларның, шагыйрьләрнең әти-әниләрен бик хөрмәтләп искә алганнарын белдек. Инде үзебезнең иҗат капчыкларын чишик. (Укучылар үзләре иҗат иткән шигырьләрен укыйлар.)

3. Бер гаиләдә әби-бабай, әти-әниегез һәм син яшисез. Сиңа күңеллеме? Ни өчен?

— Үземә генә күңелсез. Күңеллерәк булсын өчен, энекәш, сеңелкәшләр кирәк.

4. Р. Миңнуллинның «Энекәш кирәк миңа» яки «Минем сеңелкәшкәем» шигырен алдан тәкъдим иткән укучы яттан сөйли.

— Бала белән өйгә ямь керә, бишек җыры керә. Бишек җырын күбрәк кем җырлый? Кайсыгыз бишек җыры белә? (Курчакны тирбәтеп җырларга була.)

5. Р. Миңнуллинның «Өйрәнә» шигырен укыту.

— Балалар да, өлкәннәр дә дус, тату яшәргә тиеш.

6. Р. Миңнуллинның «Үзебез генә калгач» дигән шигырен тыңлау.

7. Гаиләдә әле тагын башка кешеләр дә булырга мөмкин. Мәсәлән, кем ул килен? (Абыегызның яки энегезнең хатыны.)

— Сезгә кем була? (Җиңгәчәй, җиңги.)

— Кем ул кияү? (Апагызның яки сеңлегезнең ире.)

— Сезгә кем була? (Өлкәнрәк булса, җизни.)

— Кем ул кода, кодача? (Киленнең яки кияүнең туганнары.)

8. Димәк, гаилә бик зур икән. Менә сезнең өегез. Сез үзегез белән яшәргә кемнәрне алыр идегез? (Рәсем күргәзмәсе оештырыла. Гаилә әгъзаларының фоторәсемнәрен дә алып килергә була.)

IV. Дәрескә нәтиҗә ясау.

Татар календаренда гаилә темасына бик күп хәдисләр (ягъни киңәшләр) бирелгән. Менә сезне шулар белән таныштырасы килә.

1. Ата-анагызның сүзләрен тыңлагыз, хәтерләрен калдырырлык, аларны борчырлык эшләрдән сакланыгыз.
2. Аларны һәрвакыт хөрмәт итегез, тәрбияләп яшәгез.
3. Вафат булгач, хөрмәт белән озатыгыз, дусларын якын күрегез.
4. Туганнарыгызның яннарына барыгыз, үзләрен чакырыгыз, хәлләрен белешеп торыгыз, бүләкләр җибәрегез.
5. Гаиләнең олугларын хөрмәт итегез, кечкенәләренә мәрхәмәтле һәм шәфкатьле булыгыз.
6. Нәсел-нәсәбәгезне белегез, кардәшләрегезгә рәхимле булыгыз.

V. Өй эше.

Үзегезнең әби-бабаларыгызның исемнәрен (шәҗәрә) сорап, язып алып килегез.

32 нче дәрес

Тема: Нәсел җебе — шәҗәрә.

Максат: 1. Балаларда борынгы әби-бабалары белән кызыксыну уяту. 2. Аларга карата мәхәббәт хисләре тәрбияләү. 3. Шәҗәрәләр төзергә өйрәтү.

Материал: Ш. Галиевнең «Тарихтан сабак», «Кыйбланамә» шигырьләре.

Җиһазлау: Танылган кешеләрнең, булса — балаларның үз гаиләләренең шәҗәрәләре.

Дәрес барышы

I. Дәреснең темасы һәм максаты белән таныштыру.

II. Яңа материал өстендә эш.

III. 1. Ш. Галиевнең «Тарихтан сабак» шигырен уку һәм сорауларга җавап бирү.

— *Шәҗәрә* сүзен ничек аңлыйсыз? (Җавaптан соң.) Малай бабаларын белгәнме?

2. «Нәсел җебе», «нәсел агачы» турында төшенчә бирү.

— Сез әбиегезнең, бабагызның эти-әниләрен беләсезме? Алар кайсы яктан? Аларның эти-әниләре кемнәр булган? Беркем дә үзеннән-үзе генә барлыкка килми. Һәркемнең эти-әнисе бар. Әти-әниләрегезнең дә эти-әнисе булган. Без — нәсел агачы дип аталган агачның бер ботагы. (Бер нәсел агачы үрнәге карау.)

3. Без хәзер үзебез нәсел агачы ясап карыйбыз. Иң аска — тамыр турына — квадрат ясыйк. Анда һәркем үз исемен язсын. Агачның кәүсәсе ике ботакка аерыла. Бу ботакларга да квадрат ясыйбыз. Бер квадратка — әтиегезнең исемен, икенчесенә әниегезнең исемен язабыз. Шунда ук аларның туган елларын, фамилияләрен, туган җирләрен, эш урыннарын язабыз. Агачны тагын да озынайтабыз. Зур ботаклар тагын ике кечкенә ботакка аерыла. Кечкенә ботаклардагы квадратларга әбиләр һәм бабайлар турында язабыз. Әгәр яза алмасагыз, эти-әниләрегездән сорашып языгыз. Мөмкин кадәр еракка китеп, нәсел җебен белергә тырышыгыз.

4. Физкульттәнәфес.

5. Укучыларның нәсел агачын анализлау.

— Нәсел агачының һәр ботагы икегә аерыла. Алдагы ботак тагын икегә аерыла. Шулай итеп, ботак саны буй саен ике тапкыр артып бара. Ботаклар саны шулай арта:

1—2—4—8—16—32 ...

Һәр кешенең мenә никадәр әби-бабасы бар.

6. Берәр атаклы кешенең шәҗәрәсе белән танышу.

— Әти-әниләрнең балалары берничә булырга мөмкин. Бер әти-әни балаларын *бертуганнар* дип атыйлар. Әти-әниләре бертуган булса, *туганнан туган* дип атыйлар. Бу шәҗәрәне борынгыдан ясап калдырганнар. Ул балаларга күчкән. Балалар аны дәвам иткәннәр.

7. Физкульт-музыкаль тәнәфес.

III. Ныгыту күнегүләре.

Ш. Галиевнең «Кыйбланамә» шигырен уку һәм анализлау.

IV. Өй эше.

Нәсел агачын, әти-әниләрдән, әби-бабайлардан сорашып, мөмкин кадәр дөрес һәм озак дәвам иттерү.

<u>33 нче дәрес</u>

Тема: Йомгаклау дәресе.

Максат: 1. Ел буе өйрәнгәннәрне кабатлау. 2. Сөйләм телен баету. 3. Фән белән кызыксынуны арттыру.

Материал: Р. Фәйзуллин шигыре; мәкальләр.

Дәрес барышы

I. Дәреснең темасы, максаты белән таныштыру.

II. Ел буе өйрәнгәннәрне кабатлау.

1. Үзегез белән җитди һәм күңелле итеп таныштырыгыз.

2. Бу уку елында үзең белән булган иң кызык вакыйганы сөйләтү.

3. «Мәкаль әйтеш» уены. Калганын әйтеп бетер:

— Бер тиенлек куян, ...

— (Ун тиенлек зыян.)

— Ачтан үлсәң дә, ...

— (Ата-анаңны ташлама.)

— Ачы булсаң, тоздай бул, ...

— (Татлы булсаң, балдай бул.)

4. Дәреслектә бирелгән өзектән хаталар таптыру. Аны үзләренең гаиләләре белән чагыштыру.

5. Кроссвордны чишү.

(Җиңги, бабай, әни, килен, әти.)

6. Ситуациягә мәкаль сайлау.

Ләйлә уку дәресендә бирелгән шигырьне ятламаган. Укытучы бүген тагын бер шигырьне яттан өйрәнергә бирде. Ләйлә

ике шигырьне ятлый алмачагын әйтте. Укытучы аңа нәрсә дияр:

1) Калган эшкә кар явар.

2) Тырышкан табар, ташка кадак кагар.

3) Үзе егылган еламас.

Җавапларыгызны дәлилләгез.

III. Йомгаклау. Р. Фәйзуллинның һәм Ф. Яруллинның дәреслектә бирелгән шигырьләрен укып анализлау.

УКУЧЫЛАРНЫҢ БЕЛЕМНӘРЕН ТИКШЕРҮ ӨЧЕН ТЕСТЛАР

I. Сөйләм һәм фикерләү

1. *Сөйләм төрләрен билгелә:*

а) гади сөйләм, фәнни сөйләм
б) фәнни сөйләм, әдәби сөйләм
в) гади сөйләм, фәнни сөйләм, әдәби сөйләм

2. *Текстларны тап:*

а) «Шүрәле» балеты
б) күнегү, изложение, телефоннан сөйләшү
в) хикәя, шигырь, экият

3. *Артык сүзле юлны тап:*

а) дәфтәр, китап, урындык
б) каен, усак, чыршы, нарат
в) тәрәзә, түшәм, идән, ишек

4. *Сүз ни өчен кирәк?*

а) кешене тәрбияләү өчен
б) тәрбияләү, хәбәр итү, тынычландыру өчен
в) җөмлә төзү өчен

5. *«Урманда» темасы буенча тар темаларны тап:*

а) «Яз көне», «Җиләк җыйганда», «Күңелле»
б) «Аю һәм бүре», «Гөмбәләр җыябыз», «Чаңгы шуганда»
в) «Җиләк җыйганда», «Урман һавасы шифасы», «Агачлар арасында»

6. *Нәрсә ул аннотация?*

а) әсәрнең төп фикерен кыскача сөйләү
б) язучының биографиясе
в) әсәрнең эчтәлеге

7. *Кагыйдәне тап:*

а) Казан, Алабуга, Мәскәү — шәһәрләр
б) *Казан, Алабуга, Мәскәү* сүзләре баш хәрефтән языла, чөнки алар — шәһәр исемнәре
в) Казан, Алабуга, Мәскәү шәһәрләре безгә ерак

8. *А. Алиш әкиятләрен билгелә:*

а) «Су анасы», «Кәҗә белән сарык»
б) «Сертотмас үрдәк», «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар»
в) «Кызыл калфак»

9. *Татарстанда чыга торган газеталар:*

а) «Сабантуй», «Көмеш кыңгырау», «Юлдаш»
б) «Ялкын», «Ватаным Татарстан»
в) «Сабантуй», «Казан утлары»

10. *Нәрсә ул рубрика?*

а) мәкалә исеме
б) газета исеме
в) үзеннән соң бирелгән барлык язмаларның гомуми исемлеге

II. Аралашу культурасы

1. *Котлаулар нинди өлешләрдән тора:*

а) эндәш, тәбрикләү, теләкләр
б) бүләк бирү
в) телефоннан котлау

2. *Туган көне белән котлап, кешегә нинди букет бүләк итәргә мөмкин?*

а) нинди булса да ярый
б) букеттагы чәчәкләр саны так булырга тиеш
в) чәчәкләр парлы булырга тиеш

3. *Кунаклар килгәч, үзеңне ничек тотарга?*

а) ничек тотсаң да ярый, син бит үз өеңдә
б) бераз гына мактанып алырга мөмкин
в) кунакларыңның һәрберсенә бик игътибарлы булырга кирәк

4. *Кунакка син ни өчен барасың?*

а) дусларың белән аралашырга
б) тәмле итеп ашарга
в) үзеңнең уңышларың турында сөйләргә

5. *Табындагы ашны иң беренче булып кем ашый башларга тиеш?*

а) кем җитешсә — шул
б) андый кагыйдә юк
в) гаиләдәге өлкән кеше

6. *Татар халык ашларын билгелә:*

а) чәкчәк, бавырсак, коймак
б) аш, чәй, бәлеш
в) өчпочмак, белен, пәрәмәч

7. *Чәчәк исемнәрен белдергән кеше исемнәрен тап:*

а) Асия, Нурия, Рөстәм
б) Энҗе, Лилия, Миләүшә
в) Зөбәрҗәт, Чулпан, Айсылу

8. *Нәрсә ул автобиография?*

а) үзең турында үзең сөйләү
б) синең турында иптәшең сөйләү
в) кеше турында ни белсәң, шуны сөйләү

9. *Татар халкының милли бәйрәмен билгелә:*

а) Кышны озату
б) Сабантуй
в) Яңа ел

10. *Татар исемнәренең тарихын өйрәнгән галимнең исемен ата:*

а) Гомәр Саттаров
б) Роберт Миңнуллин
в) Фәнис Яруллин

Логик фикер йөртүне үстерү өчен табышмаклар, шарадалар.

1. Эт нигә өрә? *(Сөйләшә белмәгәнгә)*
2. Бер тавык — тавык,
   Ике-өч тавык нәрсә? *(Тавыклар)*
3. Урман белән тау арасында нәрсә бар? *(Белән)*
4. Сөяге юк, үзе тере, үзе сөйли. Ул ни? *(Тел)*
5. Барда юк,
   Юкта бар. *(«Ю» хәрефе)*
6. Әниеңнең сеңлесенең җизнәсе сиңа кем була? *(Әтиең)*
7. Шалканны кайчан чәчәләр? *(Беркайчан да. Орлыгы гына чәчелә)*
8. Нинди шәһәр исеме суда йөзә? *(Алабуга)*
9. Дәрес башында нәрсә ишетәбез? *(«Д» авазын)*
10. Кайбер кешене нигә саран диләр? *(Юмарт булмаганга)*

Кулланылган әдәбият

1. *Х. Госман, З. Мәҗитов.* «Әдәбият теориясе». Казан, 1980.
2. *Г. Ибраһимов.* «Алмачуар». Казан, 1990.
3. *Л. Лерон.* «Транзистор үч ала». Казан, 1989.
4. Татар халык табышмаклары. Казан, 1970.
5. «Агыла да болыт агыла». Казан, 1993.
6. Балалар календаре. Казан, 1990.
7. *Х.-К. Андерсен.* «Әкиятләр». Казан, 1989.
8. *Г. Хәсәнов.* «Елның дүрт фасылы». Казан, 1991.
9. *Р. Хафизова.* «Актәпи ник моңая».
10. *Г. Мөхәммәтшин.* «Без әле җирдә яшибез». Казан, 1982.
11. *А. Алиш.* «Сайланма әсәрләр». Казан, 1967.
12. *Р. Газизов.* «Җиләкле алан».
13. Нәниләргә бүләк.
14. «Балалар фольклоры».
15. *И. А. Крылов.* «Аккош, кысла һәм чуртан».
16. «Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре». Казан, 1959.
17. «Раушан күзгә» (төзүчесе Р. Ш. Халикова). Казан, 1993.
18. *В. Нуриев.* «Бүре кадәр бүрек». Казан, 1991.
19. *Р. Гыйззәтуллин.* «Көтелмәгән сорау». Казан, 1990.
20. *Д. Аппакова.* «Кечкенә Бануның тарихы». Казан, 1990.
21. *Гомәр Саттар-Мулилле.* «Татар исемнәре ни сөйли». Казан, 1998.
22. Татар халык әкиятләре. Казан, 1989.
23. *Ф. Яруллин.* «Яз гөлләре». Казан, 1996.
24. *Ш. Галиев.* «Камырша».
25. *Э. Шәрифуллина.* «Җитәкләшеп җил белән».
26. *Р. Харис.* «Матур өй».
27. Хуҗа Насретдин мәзәкләре.
28. «Уйныйбыз да, җырлыйбыз да» (төзүчесе С. Әхмәтов). Чаллы, 1991.
29. «Татар балалар поэзиясе антологиясе». Казан, 1980.
30. «Совет Татарстаны язучылары». Казан, 1986.

Учебное издание

Хасанова Марьям Хасановна
Сафиуллина Гульсина Мидхатовна
Гарифуллина Миляуша Ярулловна
Мухаметзянова Амина Габдульбаровна

УРОКИ РИТОРИКИ В 3 КЛАССЕ

Методическое пособие для учителей

(на татарском языке)

Редакция мөдире *Р. И. Раскулова*
Редакторы *Н. К. Нотфуллина*
Тышлык рәссамы һәм бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы *Ә. С. Трофимова*
Компьютерда биткә салучысы *Р. Ф. Мөбарәкҗанова*
Корректоры *Т. Н. Сәгъдуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 29.01.2004.
Форматы 60×90 1/16. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы.
Офсет басма. Басма табагы 4,0. Нәшер-хисап табагы 2,68.
Тиражы 2000 д. Заказ С-335.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Издательство «Магариф». 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты».
420111. Казан, Бауман урамы, 19.